**Укытучы:** Укучылар, безнең бүгенге дәресебез гадәти түгел. Без сезнең белән китап өстендә утырган бер илдә булырбыз. Илнең исемен белү өчен менә шушы төшенчәгә туры килгән сүзне табарга кирәк.
**Көтелгән җавап:** Алмашлык.
Ни өчен китап эчедә шундый шәһәр бар дип уйлыйсыз, китапка нәрсәгә сон ул?
**Көтелгән җавап:** Китапка матур итеп язу өчен.
**Укытучы** Димәк, бүген нинди уку мәсьәләсе куела?
**Көтелгән җавап:** алмашлыклар турында белем һәм күнекмәләрне камилләштерү, аларны кабатлау өстендә эшләү..
Дәфтәрләргә бүгенге чисо, сыйныф эше, тема языла.
**Укытучы:**Укучылар, бүгенге дәрескә куелган уку мәсьәләсен хәзер этаплап чишәрбез. Һәр биремне эшләгәннән соң, үзегезгә билге куярсыз. Әлеге эштә безгә юл картасы ярдәмгә килер.Безгә шәһәр белән танышу өчен серле китап ярдәмгә килер, Ул 7 битле. Карта буенча юлдан тайпылмыйча барсак китапның соңгы битендә без хәзинә таба алачакбыз.Бу китап ни өчен 7 биттән тора икән?
**Көтелгән җавап:** Алмашлыкның 7 төркемчәсе бар.
**Укытучы:** Димәк, безнең узган теманы адымлап ныгытуыбыз алга барырга, тагын кызыклы, яңа нәрсәләр белергә ярдәм итәр.
III**. Материалны ныгыту. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Безнең алдыбызда беренче бит.Битне ачу өчен, аның исемен атарга кирәк. Моның өчен безгә әлеге төшенчәгә туры килгән алмашлыкны табырга кирәк. “Сөйләүчеләр,тыңлаучылар, сөйләмдә катнашмаган, әмма шулар турында сүз барган зат яки предметны белдерүчеләр.”

**1нче бит**

**“Зат алмашлыгы”** урнашкан.

**Юл картасыннан** 1 номерлы биремне эшлик. Бирелгән сүзләр арасыннан алмашлыкларны табырга. Зат алмашлыкларын язып ал, затын, санын, килешен яз.

Мин, ул, сезне, син, безнең, энә, кайчан, чыга, сиңа, кемдер,аларда, су, ләкин, әкрен.

**Нәтиҗә ясала!!!**

2. **нче бит**

**Укытучы.** Биремне үти алдыгыз. Әйдәгез юлыбызны дәвам итик, менә **икенче бит**. Икенче биттә безне нинди алмашлык көтә икән?

Затка, предметка, аның билгеләренә күрсәтә

**Көтелгән җавап: Күрсәтү алмашлыгы**

**Укытучы :Әйе, без “Күрсәтү алмашлыгы ”** на килеп кердек. (парларда эш)

Юл картасыннан Икенсе биремне үтик.Бирелгән күрсәтү алмашлыкларын килеш белән төрләндер.

<u>Көтелгән җавап.:</u>

| **I** | **II** |
|---|---|
| Бу | Шул |
| **Б.к. бу** | **Б.к. шул** |
| **И.к. моның** | **И.к. шуның** |
| **Ю.к. моңа** | **Ю.к. шуңа** |
| **Т.к. моны** | **Т.к. шуны** |
| **Ч.к. моннан** | **Ч.к. шуннан** |
| **Ур.в. к. монда** | **Ур.в. к. шунда** |

**А (I) һәм Б (II) парыгыз** белән дәфтәрләрегезне алыштырыгыз. Иптәшегезнең эшен тикшереп, билге куясыз. Бер хатасыз эшкә – “5”ле, бер хаталы эшкә – “4”ле, ике хаталы эшкә – “3”ле.

**3. Өченче капка.**

Сорау формасында зат яки предметларга, аларның билгеләренә, саннарына һәм хәлләренә күрсәтәләр

**Көтелгән җавап: сорау алмашлыгы.**

Димәк, безне элеккеге танышларыбыз – сорау алмашлыклары белән очрашу көтә. Ни өчен элеккеге танышлар дидем? (укучылар җавабы)

Дөрес, исем, сыйфат, сан, рәвеш сүз төркемнәрен өйрәнгәндә аларның сорауларын карадык. Бу эшләрне **“Сорау алмашлыгы” бүлеге** башкара.

Безнең элеккеге танышларыбыз сораулар әзерләгән.

1. Алмашлыклар ясалышы ягыннан ничә төрле була? (5)
2. Алмашлыкның ничә төркемчәсе бар? (7)
3. Бүген атнаның ничәнче көне? (5)
4. Беркем алмашлыгы ничә тамырда тора? (2)
5. Укучы сүзендә ничә иҗек бар? (3)
6. Татар теле кабинеты ничәнче катта? (2)

**4**. **нче бит**

**Укытучы.** Менә дүртенче бит янына килеп җиттек. Ишектә түбәндәге язулар эленгән.

- “Монда беркем дә юк”.
- “Беркемгә дә ачмыйбыз”.
- “Бернинди дәгъвалар кабул итмибез. **”.**

Менә сиңа хәлләр! Инде нишлибез? Игътибар белән тагын бер кат укыгыз әле. Бәлки, мин дөрес күрмимдер? Безгә бит капканы ачарга кирәк. Бу капканың исеме ничек аталыр икән? Әлбәттә “**Юклык алмашлыклары”.**

Текст өстендә эш

Мин кулыма китап алам...

(1) Без - китаплы халык. (2) Татар халкы гыйлемле булган, китап укыган.

(3) Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән кулъязма китаплар шул хакта сөйли.

(4) Кулъязмаларны күчереп язучы осталар барлыкка килгән. (5) Хәзергечә әйтсәк, китапларны тиражлаучылар була.

(6) Аннан басма китаплар чоры башланган. (7) Безнең әби-бабайларыбыз үз телләрендә белем алганнар, шул ук вакытта фарсыча да, гарәпчә дә белгәннәр. (8) Шунысы мөһим: без үзебез генә белемле булып калмаганбыз, мәгърифәт нурларын башка тугандаш халыкларга да таратканбыз…

( 9) Бүгенге көндә безнең төп рухи таянычыбыз китап булырга тиеш! (10) Китапсыз күңел - буш күңел, китапсыз йорт - нурсыз йорт, китапсыз милләт - киләчәксез милләт. (11) Бәхетебезгә, без андыйлар түгел! (12) Әлегә...

(Р. Миңнуллин*)

Биремнәр

1.Беренче җөмләдә алмашлык нинди җөмлә кисәге булып килгән?

2. 6-8нче җөмләләрдән I зат, берлек сан, иялек килешендә булган алмашлык кулланылган җөмләнең санын яз.

3.9 нчы җөмләдәге алмашлыкны башка җөмлә кисәге белән алыштыр һәм үзгәртеп яз.

4.Текстның соңгы җөмләсен ничек аңлыйсыз? Бер- ике җөмлә белән үз фикерегезне языгыз.

**Физкультминут. Китап бирү уены(китапны ничек тотарга, мәкальләр әйтәләр)**

**5. нче бит**

**Укытучы.** Бишенче биткә дә килеп җиттек. Бу нинди тамгалар тагын.

Әллә?, ?-дыр, ?-дер, ?-тыр, ?-тер

**“Билгесезлек алмашлыгы” (төркемнәрдә эш)**

Юл картасындагы 5 номерлы беремне эшлибез.. Биремне кунакларга якын утырган укучы укый.

Кем? Нәрсә?Нинди?Кайсы? Ничә? Ничәнче?Кайчан? Ничек?

Бирелгән сорау алмашлыкларыннан билгесезлек алмашлыгы ясап языгыз.

Ә хәзер тест эшләп алабыз. Plickers

**6нчы бит**

**Укытучы.** 6 нчы биткә якынлаштык

“Затларны, предметларны гомумиләштереп белдерәләр”

**Көтелгән җавап:** Билгеләү алмашлыклары (дәреслек белән эш)

Дәреслектән 191 күнегү. Билгеләү алмашлыкларын гына сайлап язасыз.

**Һәрвакыт,бөтен, һәммә, һәркем,**

Тикшерү.Үзбәя

**7нче бит**

**Укытучы.** Җиденче бит безне предметның кемнеке, кайсы затныкы икәнен белдерә торган алмашлыклар каршы ала. Димәк, кайсы алмашлыклар бирелә?

Әйе, **“Тартым алмашлыклары” бүлеге.** Монда безне түбәндәге эш көтә.

Мин хәзер алмашлык әйтәм, сез килешәсезме? Килешсәгез басасыз, килешмәсәгез утырасыз.

Кемдер – юклык алмашлыгы (билгесезлек)

Әллә кем – юклык алмашлыгы (билгесезлек)

Берәү – билгесезлек алмашлыгы (билгесезлек)

Һичнәрсә – юклык алмашлыгы (юклык)

Беркая – билгесезлек (юклык)

Һич - юклык алмашлыгы (юклык)

Нәтиҗә!

**Укытучы. Менә , укучылар, без мәгарәгә килеп тә җиттек.** Ләкин аның ишеге дә ябык, ә анда 4 саны язылган. Төркемдә эш (һәр төркемгә җөмләләр язылган бит бирелә, алмашлыклар нинди җөмлә кисәкләре булып киләләр)

Мин укыйм. ( ия)

Бу ул! (хәбәр)
Андый сүз әйтмә. (аергыч)
Тегеләрдән зур сәлам. (тәмамлык)
Менә шулай языгыз. (хәл)
7 яшендә Асияне – мине – чит шәһәргә алып китәләр. (аныклагыч**)**

**Нәтиҗә**

Менә безгә мәгарә ишекләре ачылды, менә ул хәзинә, әлбәттә китаплар. Укучылар ничек уйлыйсыз, ник без китапларны зур хәзинә дип атыйбыз?

Укытучы Г.Тукайның "Китап" шигырен укый. Укучылар, китап белән дус булыгыз, аңа кадер- хөрмәт белән карагыз, бу хәзинәне кулыгыздан ычкындырмагыз.

**IV. Рефлекция , бәяләү**

1.Әйдәгез йомгак ясыйбыз.

Сорауларга җавап бирү.

1 сорау. Нинди сүз төркеме алмашлык дип атала? Укучы. Исемне, сыйфатны, сан һәм рәвешне алмаштырып килә торган мөстәкыйль сүз төркеме алмашлык дип атала.

2 сорау. Ясалышлары ягыннан алмашлыклар ничә төрле була? Укучы. Тамыр, кушма, парлы, тезмә, ясалма алмашлыклар була.(5)

3 сорау. Алмашлыкларның мәгънәләре ягыннан ничә төркемчәсе бар? Укучы. Җиде төркемчәгә бүленә: зат, тартым, күрсәтү, сорау. Билгеләү, билгесезлек, юклык алмашлыклары..

4 сорау. Алмашлыклар җөмләдә нинди җөмлә кисәкләре булып килергә мөмкин? Укучы. Ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык булып килергә мөмкин.

5 сорау. Алмашлыклар сөйләмдә нинди әһәмияткә ия? Укучы: Алмашлыклар сөйләмне җыйнак һәм матур яңгырашлы итә. Урынсызга бер үк сүзне кабатлаудан коткаралар.Төрләнмиләр.

2. **Билгеләр кую: Үзбәя һәм укытучы бәясе.**

Юл карталарында билгелиләр.

1. Мин бүген дәрестә...белдем.
2. Миңа ... кызык булды.
3. Миңа ... кыенрак булды.
4. Мин ... өйрәндем.

Үзегезнең билгеләрегезне карагыз. Әгәр бишле билгесе, җыя алмаган булсагыз, борчылмагыз "Алмашлык" иле сезгә ярдәмгә килер.

**V . Өй эше**

а) мәҗбүри – 191 нче күнегү, алмашлыкларның төркемчәләргә бүлеп яз;
б) ярымиҗади – китап турында мәкальләр, шигырьләр табыр килергә;
в) иҗади бирем – алмашлыклар кулланып, "Минем яраткан китабым" дигән хикәя төзергә.

**Габдрахманова З.Б.**
Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының
"Гомуми үсеш бирүче төрдәге Кариле балалар бакчасы"
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе
музыка җитәкчесе
югары квалификация категорияле

## ЧИШМӘ ЯНЫНДА – КИЧКЕ УЕНДА

**Дидактик материал төре:** Мәктәпкә әзерлек төркемендә фольклор бәйрәм эшкәртмәсе
**Максат:**

1)Балаларның күңелләрендә татар халкының җырлы-моңлы биюле уеннары аша гасырлар буенча үткәрелгән татар халык йола бәйрәмнәрен саклап калу;
2) Киләчәк буынны милли традицияләр нигезендә тәрбияләү;
3) Уен барышында җанлы диалог, һәртөрле сөйләшүләр, көлке, җор сүз, импровизация аша балаларның сөйләм телен үстерү, фикерләү сәләтләрен арттыру;

**Бурычлар:**

1) Балаларны уен аша татар халык йолалары белән таныштыру;
2) Киләчәк буыннарны милли традицияләрдә тәрбияләү нигезендә халкыбыз рухының аерылгысыз бер өлешен тәшкил иткән татар халык уенлы- сүзле җырларының югалуына юл куймау;
3) Халкыбызның милли трдицияләрен җыйнау, матбугатта бастыру, аларга кабаттан "җан өрү" хәстәрен күрү;

**Җиһазлау:** Агачлар, чишмә, эскәмия,чиккән сөлгеләр, чиләкләр, кул эшләре, ЭМТЧ - диск.

**Кошлар тавышы, челтерәп аккан чишмә тавышы,чишмә янындагы эскәмиягә әби (тәрбияче) чыгып утыра.**

**Әби (сокланып).** Әй,бәрәкалла,чишмә тавышы..... Э-х,бар иде яшь чаклар,чишмә суы аккан кебек,челтерәп агып,үтте дә китте.

Әй-й....,бигрәкләр дә сакламыйлар шул хәзер чишмә буйларын, күр, никадәр чүп-чар. Каяле, үземә кайтып чиләк алып килеп бу чүпләрне жыештырыйм булмаса **.(китә)**

**Салмак кына көй яңгырый. Көянтә-чиләк күтәргән кызлар (балалар) чыгалар, аяк очларында биеп әйләнәләр дә, чишмә тирәсендә туктап калалар.**

**Кыз**: Кызлар, карагыз әле, күпме чуп-чар. Әйдәгез, чүпләрне җыештырып, бәйләп куябыз, җил теләсә-кая очыртмасын.

**Кызлар:** Әйдәгез, әйдә...

**(Кызлар чиләк-көянтәләрен саклык белән куеп, чүп пакетына чүпләрне тутырып бәйләп куялар.Чишмәдә кулларын юалар).**

**Кыз**: Челтер-челтер чишмә ага,
Көмеш төсле сулары.
Су өстендә җем-җем итә,
Алтын-көмеш нурлары.

**Кыз**: Тау астында чишмәбез,
Су алырга төшәбез.
Татлы суын без аның
Бик яратып эчәбез.

**Вак-вак адымнар белән Әби килеп җитә:**

**Әби:** Әй, сөбоханалла, кызларым! Чишмә тирәсен җыештырып та куйгансыз бит, рәхмәт яугырлары! Кызларым, чишмә тирәсен гел чистартып, матурлап торырга кирәк. Менә мин дә бүген чишмәне матурлап яңа чүмеч алып килдем. Яле кызым, чүмечне элеп куй.

**Гармунда (**татар халык көенә) **"Авыл көе" уйнатып, бабай** (музыка җитәкчесе) **белән егетләр** (төркем малайлары) **керәләр, җилкәләренә чиккән сөлгеләр куйганнар.**

**Бабай уйнавыннан туктап, егетләргә:**

**Бабай:** Эх, менә кайда икән ул, кызларның асыллары! **(Җырлыйлар)**

**"Матур кызлар" җыры. "Әнисә"татар халык көе.**

1. Матур кызлар суга бара,
Алмалы чиләкләре.
Берсе сирень, берсе нәркиз
Берсе гөлнен зәңгәре.

2. Барысы да бер дигәннәр
Ефәк күлмәк кигәннәр.
Кайсын сайларга да белмим,
Барысы да чибәрләр.

**Малай**: Сәлам бирдек чибәр кызларга!
**Кызлар**: Сәламегезне алдык, кесәбезгә салдык! **(көләләр)**
**Малай:** Шуннан?
**Кызлар:** Тугыз ким уннан.
**Малай:** Шуннан?
**Кызлар:** Утырган да шуган.
**Малай:** Шуннан?
**Кызлар:** Кишер белән суган.
**Малай:** Шуннан?
**Кызлар:** Койрыгы тунган. **(көләләр)**
**Малай**: Әй, кызлар су алырга төшкән булып,
Нигә эшсез йөрисез?
**Кызлар:** Ә сез, гармун тартып, моң таратып,
Без – кызларны күзлисез! **(көлешәләр)**

**Малай:** Ю-ю-к, кызлар күзләргә түгел, Ак бабай белән чишмәгә сөлгеләр эләргә төштек.

**Бабай:** Әйе, яле улларым, сөлгеләребезне чишмәгә элеп куйыйк. **(сөлгеләрен эләргә баралар).** Суга сусаган юлчылар туктап, кулларын юып, сөлгеләргә кулларын сөртеп, сихәтле чишмә суларын эчеп, тәннәренә шифа алып, юлларын дәвам итсеннәр.

**Әби**: Рәхмәт яусын, Ак бабай, рәхмәт балакайлар! Утырышыйк та, чишмә яны гүзәллеген күзәтеп, сихри авазларны тыңлыйк. **(Чишмә,кошлар тавышы,талгын көй башлана)**

**Әби:** Без яшь киленнәр булган чакта, кышкы озын кичләрдә өйләребездә лампа яктысында кул эшләре белән утыра идек.

Карлар эреп, җирләр кипкәч, авылның уңган килен-кияүләре кул эшләрен алып, чишмә янына килеп кич утыра идек, җырлар җырлап, биеп күңел ачып, өйләребезгә кайтканбыз. Шулай ук һәр төбәкнең җырларда макталып, шигъри юлларга күчкән бер урыны була. Безнең якның да иң матур урыны шушы чишмә аланы булган. Халык аны яратып **"Чишмә аланы"** дип атаган.

**Җыр: "Чишмә җыры." Г.Шакирова сүзләре Р. Закирова көе.**

**Әби:** Рәхмәт, балакайлар. Карале, Ак бабай, без дә яшь чакларны искә алып, киленнәрне чакырып, кул эшләре эшләп кич утырыйкмы әллә?

**Бабай**: Әйе шул, бик әйбәт булыр! Балалар, без килгәнче сез китмәгез, әбиегез белән без бик тиз килербез.**(китәләр)**

**Малай**: Дуслар, тик утырмыйк, әйдәгез **"Әйтешле"** уйныйбыз.**(кара-каршы басалар)**

**Раил**: Әлинәү!
**Алинә**: Әү?
**Раил**: Авызын дәү!
**Мәрьям**: Көлмә кешедән, авызың өшегән!
**Инзилә**: Нияз! Кабартма -дип әйт.
**Нияз**: Кабартма.
**Инзилә**: Битләреңне кабартма!
**Динара**: Кәрим! Сөт – дип әйт.
**Кәрим**: Сөт.
**Динара**: Авызыңны сөрт!
**Кызлар бергә**: Эх,сез малайлар,
Түбәдәге калайлар!
**Малайлар:** Эх, сез кызлар,
Һавадагы йолдызлар!
**Малай**: Ярый, дуслар, үпкәләшмик, әкият сөйлим, утырыгыз.
"Борын-борын заманда,
Яшәгән ди, әби белән бабай.
Аларның өйләре булган ди, таштан.
Кәҗәләре йөргән ди, баштан.

Этләре булган ди Каштан”
Сөйлимме яңабаштан?
**Балалар**: Ю-ю-ю-юк!
**Кыз**: Чү, туктагыз, тик утырыйк, әнә Әби белән кунаклар килә.

**Залның бер ягыннан әби белән кыз-килennәр** (тәрбиячеләр) **кул эшләре, ләгәннәр тотып киләләр дә, эскәмиягә утыралар.**
**Залның икенче ягыннан бабай белән малайлар җырлап керәләр дә, малайлар һәм кызлар кара –каршы басып җырлыйлар.**
**Шаян җыр “Челтәр элдем читәнгә”(татар халык жыры).**
Челтәр элдем читәнгә
Җилфер-җилфер итәргә.
Без килмәдек буш китәргә.
Килдек алып китәргә.

**Кызлар**: Алын алырсыз микән,
Гөлен алырсыз микән,
Урталарга чыгып сайлап
Кемне алырсыз минән?

**Малайлар:**
Алларын да алырбыз,
Гөлләрен дә алырбыз,
Күңелебезгә кем ошаса-
Шуны сайлап алырбыз.

**Кызлар:**Уйнасак та,җырласак та,
Гармун кулларыбызда.
Алсу гөллэр чәчәк атсын
Йөргән юлларыбызда.

**Малайлар кул эшләрен җәймәгә җәеп куялар. Ә кызлар киленнәр янына барып утыралар.**
**Малай:** Әйдә, бабай, тизерәк,
Эшләгәнне күрсеннәр.
Безне авыл кызлары -
Бигрәк өлгер, дисеннәр!
**Бабай гармунын куеп малайлар янына тукмаклар шомартырга эшләргә утыра. Әби дә киленнәр, кызлар белән эшкә утыралар.**
**Әби:** “Агачны яфрак бизәсә – кешене хезмәт бизи,”-ди халык мәкале, әйдәгез мәкаль әйтеш уйныйбыз. Мин башын әйтәм, сез ахырын әйтерсез.
Агач җимеше белән....................кеше эше белән матур.
Эше юкның............................ашы юк.
Хөнәрле үлмәс..................хөнәрсез көн күрмәс.
Аз сөйлә..........................күп эшлә.
Эш беткәч................уйнарга, җырларга ярый!
**Бабай гармунын ала да, уйнап җибәрә.**
**Татар халык көе, сүзе. “Күрсәт әле үскәнем”.**
**Кызлар:** Күрсәт әле бабакай,
Ничек тукмак ясыйлар?
**Малайлар:** Менә шулай, менә шулай
Шулай тукмак ясыйлар.
**Малайлар:** Күрсәт әле әбекәй,
Ничек йомгак урыйлар?
**Кызлар:** Менә шулай,менә шулай
Шулай йомгак урыйлар
**Бергә:** Андый матур тукмакны
Бездә ясый малайлар.
Андый тигез йомгакны

Бездә урыйлар кызлар.

**Әби:** Карагыз әле, балакайларым, сез эш эшләгәндә, киленнәр кер юганда эш коралларыннан мин нindидер көй ишеткән кебек булдым, әллә мин әйтәм, гармунга кушылып, без дә эш коралларыннан көй чыгарып карыйкмы? **(балалар һәм киленнәр үзләренә билгеләнгән эш кораллары алалар да, гармунга кушылып "эш -уен коралларында "уйныйлар).**

**Әби**: Булдырдыгыз, рәхмәт! **(Әби малайларның шомарткан тукмакларын карап чыга)** булдырып та эшләгәнсез, егет икәнсез! Менә бу тукмагыгыз миңа бигрәк тә ошады! Әйдәгез,**"Тукмаклы"уенын уйнап алабыз.**

**Бала: (тукмакны тотып):** Игътибар белән тынлагыз,
"Тукмаклы" уйнатабыз.
Бирем кемгә икәнлекне,
Тукмактан сайлатабыз. **"Такмаза"татар халык сүзләре.**

**"Тукмак" уены уйнала.Тукмак әйләндергәндә кемдә туктый,шул кешегә җәза бирелә**(балалар теләге буенча җәза бирелә,уен 3 тапкыр уйнала)

**Малай:** Әйдәгез,парлашып җырлап-биеп алабыз.

**Җырлы-биюле уен: " Куш кулым" татар халык сүзләре, көе.**

**Чишмә буенда кайнашкан әби:** Ай, рәхмәт яугырлары! Бигрәкләрдә булдырып уйныйсыз инде...Киленнәр әллә сез дә берәр уен уйнап курсәтәсезме, әле онытырга өлгермәгәнсездер?

**Киленнәр:** Сез рөхсәт итсәгез, бик тә рәхәтләнеп уйныйбыз.

**"Кулъяулык салыш» татар халык уены.**

**1 килен:** Уенның тәртибен аңлатам. **Түгәрәктә биеп йөрибез, уртада кулъяулык болгап мин бием һәм үзем теләгән кешенең җилкәсенә кулъяулыгымны салам. Кулъяулык кемдә кала- шул җәза үти.**

**Уен 3 тапкыр уйнала.**

**Әби:** Бабакай, балалар, киленнәр, дөньябызны онытып уйнап та ятабыз бит, кояш баеп килә түгелме?

**Барысы:** Әйе, әйе...

**Әби:** Балакайларым, исегездә тотыгыз, кояш баегач беркайчан да чишмәдән су алмагыз, ярамый! Чишмә янын һәрвакыт чиста тотыгыз, чишмәләрне саклагыз, бүген уйнаган уеннарны онытмагыз, ишек алларында дусларыгыз белән, өйдә әти-әниләрегез белән уйнагыз яме.

**Малайлар чиләк-көянтәләрне кызларга кияргә булышалар. Калганнар да эш коралларын җыеп, кайтырга кузгалалар.**

**(татар халык көе "Су юлы" көенә китәләр).**

**Әби:** Бөртекләп вә берәмтекләп җыйган
Җәүһәрләрне барлар чак җиткән.
Гореф-гадәт, һөнәр югалмаган,
Күпме еллар, гасырлар үткән.
Илләребез имин булсын,
Матур булсын тормышлар.
Бу мирасны дәвам итәр-
Иң уңганнар, тырышлар!

**Гармун көенә салмак кына йөреп чыгып китәләр**. Татар халык көе "Төмән"

**Кулланылган әдәбият.**


1. Ягъфәров Р. Татар халкының уен фольклоры. – Казан:Иман, 2002.
2. Р.Ягъфәров. Уен –күңел бәйрәме.- Казан:Мәгариф,2009.
3. Татар халкының җырлы-биюле уеннары /Төз. Х.Гатина, сүз башы язучы И.Надиров. – Казан:Татар кит.нәшр., 1968.
4. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. – Казан:татар кит.нәшр., 1980.
5. Нәкый Исәнбәт "Балалар дөньясы"(Балалар фольклоры) җыентык, Татарстан китап нәшрияты, Казан,1970.

**6**. Нәкый Исәнбәт “Нәниләр шатлана”(Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен) Татарстан китап нәшрияты, Казан,1967.
**7.** Балалар фольклоры. Төзүче Н. Исәнбәт Казан Тат. Китап нәшрияты, 1984.
**8.** “Үткәннәргә борылып карый- карый, алга таба киләчәккә барам” Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеларында халык педагогикасы алымнарын кулланып эшләүче тәрбиячеләр өчен методик кулланма. Татарстан Республикасы Мәгариф Министрлыгы Балтач районы мәгариф бүлеге, Балтач, 1998.
**9.** “Мин бәйрәмнәр яратам” К.В. Закирова, Г.Р.Гыйләҗетдинова. **2009** ел.
**10.“**Мин яратам сине Татарстан” №2. Бәйрәм сценарийлары җыентыгы. Яр Чаллы **2012** ел.
**11. “**Мин яратам сине Татарстан” №1. Бәйрәм сценарийлары җыентыгы. Яр Чаллы **2012** ел.

**Газизова Э.И.**
Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
Казан арты милли мәгариф белем үзәге
муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе
«Арча 6 нчы номерлы урта гомуми белем мәктәбе»нең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## 8 НЧЕ СЫЙНЫФНЫҢ ТАТАР ТӨРКЕМЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЕ

| | |
|---|---|
| **Тема** | **Җөмләдә сүзләр бәйләнешен кабатлау.** |
| **Максат** | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше турында белемнәрне тирәнәйтү, гомумиләштерү;<br>1) укучыларның анализ ясау, гомумиләштерү, мөстәкыйль фикерләүләренә ирешү; алган белемнәрне куллану күнекмәләре үстерү;<br>2) эшлекле, хезмәт сөючән булырга теләк булдыру, омтылыш уяту. |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше төрләрен таный, сөйләм төзегәндә бәйләүче чараларны дөрес итеп куллана белү. |
| **Дәреснең тибы** | Белем һәм күнекмәләрне актуальләштерү дәресе. |
| **Төп төшенчәләр** | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше, бәйләүче чаралар. |
| **Предметара бәйләнеш** | Әдәбият. |
| **Эшне оештыру төрләре** | Фронталь, индивидуаль, төркемнәрдә эшләү. |
| **Чыганаклар** | • төп: дәреслек;<br>• өстәмә: слайдлар, карточкалар, күнегүләр җыентыгы, электрон дәреслек. |

**Дәрес барышы.**

**I.Оештыру, мотивлаштыру.**
-Исәнмесез. Хәерле көн, кадерле укучылар!
-Барыгызга да хәерле эш көннәре теләп, дәресебезне башлыйбыз.
-Укучылар, менә бу шигырь юлларына игътибар итегез әле:
И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкаддәс нәрсә — эш,
Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китрер җимеш.
-Ул шигырь юлларын кем язган?
-Мәшһүр якташ шагыйребез Габдулла Тукайның “Эшкә өндәү” шигыреннән бу юллар.

-Әйе. Г.Тукай ул шигырен 1911 нче елда Казан чорында язган. Бу юллар безне нәрсәгә чакыра?
-Хезмәткә.
-Әйе. Ул безнең бүгенге дәресебезгә эпиграф та.
**II.Дәрескә максат һәм бурычлар кую.Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.**

- Укучылар, сүзләр нәрсәләрдән оешалар?
- Авазлардан.
- Әйе. Ә сүзләрдән җөмлә төзү өчен, нишләргә кирәк?
- Җөмлә төзү өчен, сүзләрне бер-берсенә бәйләргә кирәк.
- Әйе. Җөмләләр төзү өчен, без җөмләдә сүзләр арасында бәйләнеш төрләрен, аларның бәйләүче чараларын аера белергә тиеш. Дөрес итеп сөйләм төзи белү – безнең иң төп максатларыбызның берсе. Без инде алдагы дәресләрдә җөмләдә сүзләр бәйләнеш төрләрен, аларга хас булган билгеләрне өйрәндегез. Димәк, бүгенге дәрестә нинди лингвистик максатларга ирешергә тырышырбыз?
- Бүген без җөмләдә сүзләр бәйләнешен гомумиләштереп кабатларбыз.Төрле биремнәр, күнегүләр эшләрбез. Алган белемнәребезгә нәтиҗә ясарбыз, җөмләдә бәйләүче чараларны куллана белергә өйрәнербез.
- Димәк, бүгенге дәресебезнең темасы нинди булыр?
- Дәресебезнең темасы: "Җөмләдә сүзләр бәйләнешен кабатлау".

**III.Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.**

- Укучылар, экранга игътибар итегез әле. Нәрсә күрәсез?
- Җөмләдә сүзләр бәйләнешенең моделен. Ләкин анда күп мәгълүмат әлегә юк.
- Әйе. Ә менә дәрес ахырында сезнең алдыгызда булган ул схема җөмләдә сүзләр бәйләнеше турында мәгълүматлар белән тутырылган булырга тиеш.
- Укучылар, җөмләдә сүзләр бәйләнешен нинди ике төркемгә бүлеп карыйбыз? Кем җавап бирә?
- Тезүле бәйләнеш һәм ияртүле бәйләнешкә.
- Ә ни өчен шулай бүленә?
- Җөмләдә сүзләрнең бер-берсенә ияреп яки бер-берсе белән тезелеп бәйләнүләренә карап.
- Бик яхшы. Дәфтәрләрегезне ачыгыз да бүгенге числоны һәм сыйныф эше дип язып куегыз. Без хәзер сайланма диктант язабыз. Мин укыган җөмләләрдән, тезүле бәйләнештә торган сүзләрне генә сайлап алып, беренче баганага, ә ияртүле бәйләнештә ачыклаулы мөнәсәбәттә булган берәмлекләрне икенче баганага язарбыз. Ә Азалия магнит тактада ике бәйләнешкә караган бәйләүче чараларны аеру күнегүләрен үтәр. Тыңлыйбыз.
- Тырышкан табар, ташка кадак кагар. Ике уйла, бер эшлә. Кешегә иң кирәге — якты йөз, җылы сүз. Эшләгән эш, әйтелгән сүз онытылмый.

| **Тиңдәш кисәкләр** | **Сүзтезмәләр** |
|---|---|
| табар,кагар<br>уйла, эшлә<br>йөз, сүз<br>эш, сүз | ташка кагар<br>ике уйла<br>бер эшлә<br>кешегә кирәге<br>якты йөз<br>җылы сүз<br>эшләгән эш<br>әйтелгән сүз |

- Хәзер парларда бер-берегезгә эшләрегезне биреп тикшертегез һәм, сыйныфташыгызның төзәтүләрен исәпкә алып, үзегезнең эшегезне бәяләп, "Үзбәя битенә" шартлы билге куегыз. Дәрес буена һәр эшегезне шулай бәяләп барырсыз.

| **Җөмләдә сүзләр бәйләнешен кабатлау** темасы буенча 8 нче А сыйныфы укучысы ____________________<br>**үзбәя бите** | |
|---|---|
| Сайланма диктант | |
| Бәйләүче чараларны аеру | |

| | |
|---|---|
| Телдән җаваплар | |
| 76 нчы күнегү | |
| Тест эшләү | |
| Җөмләдә сүзләр бәйләнеше моделен төзү | |
| Гомуми бәя | |

- Хатасыз эшегез өчен, + (плюс); төгәл эшләнмәгән эшегез өчен, сорау билгесе (?) куегыз. Дәрес буена үзегезнең танып-белү эшчәнлегезне бәяләп барырга онытмагыз.
- Ә Лилия белән Алия такта янында язып, бер-берсенең эшләрен тикшереп чыгарлар.
- Бик яхшы. Үз эшегезне бәяләгез. Һәрберегез схемаларда нинди берәмлекләр барлыкка килүеннән чыгып, ике төркемнең дә исемен язып куегыз.
- Укучылар, җөмләдә сүзләр бәйләнешенең моделенә игътибар итик әле. Нәрсә дип яздык?
- Тиңдәш кисәкләр, сүзтезмәләр.
- Азалия, сүз сиңа. Бәйләүче чараларны әйтеп чык әле. Ә без экран буенча тикшереп барабыз.
- Яхшы. Бу мәгълүматларны җөмләдә сүзләр бәйләнешенең моделенә өстәп куябыз.
- Укучылар, хәзер без схеманы тутырып бетерә алабызмы инде? Шул схема буенча җөмләдә сүзләр бәйләнеше турында үзләштергәннәрне кем сөйләп чыга?

**IV.Белем һәм осталыкларны яңа ситуациядә куллану.**

- Яхшы, укучылар, хәзер без сезнең белән әле генә сөйләгәннәрне практикада кулланып карарбыз. Дәреслек буенча 76 нчы күнегүне биреме буенча үтәү.
- Рәхмәт. Эшегезне бәяләгез.

**V.Белемне үзләштерү дәрәҗәсен ачыклау.**

Тест үтәү.

1.Сүзтезмә күрсәтелгән рәтне билгелә.

1. гөмбә
2. чебен гөмбәсе
3. зур гөмбә
4. Гөмбә үсә.

2.**Урмандагы чәчәкләр** сүзтезмәсендәге бәйләүче чараны билгелә.

1. сүз тәртибе
2. – дагы кушымчасы
3. – ләр кушымчасы
4. янәшә тору

3.**Укырга дип бару** сүзтезмәсендәге бәйләүче чараны билгелә.

1. – у кушымчасы
2. – га кушымчасы
3. дип бәйлек сүзе
4. сүз тәртибе

4.**Кызыл күлмәк** сүзтезмәсендәге бәйләүче чараны билгелә.

1. – ыл кушымчасы
2. фигыль формасы
3. янәшә тору
4. сүз тәртибе

5.**Ике бүлмә** сүзтезмәсенең исемедөрес күрсәтелгән рәтне билгелә.

1. исем сүзтезмә
2. сан сүзтезмә
3. фигыль сүзтезмә
4. сыйфат сүзтезмә.

Эшне тикшерү һәм бәяләү.

**VI.Рефлексия, үзбәя, бәя, өй эше.**

- Җөмләдә сүзләр бәйләнешеннән башка яшәп буламы? Ул ни өчен кирәк?
- Бәйләүче чаралардан башка җөмлә дә төзелмәскә мөмкин. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше фикерләребезне белдерер өчен кирәк.

- Укучылар, без дәрескә нинди максатлар куйган идек әле? Үзбәя битенә карап һәр укучы үз эшенә гомуми бәя куйсын да түбәндәге таблица буенча ирешкән максатлары һәм киләчәккә бурычлары турында сөйләп чыксын.

| | |
|---|---|
| Нәрсә белергә теләгән идем? | |
| Нәрсә белдем? | |
| Дусларыма нәрсә сөйләр идем? | |

- Өй эше итеп, 1) Һәр укучы да мәҗбүри үтәү өчен, дәреслекнең 45-46 нчы битләрендә бирелгән 75 нче күнегү;
  2) Теләгән укучыларга гына “Хезмәт сөю” темасына мәкальләр язып килү;
  3) “Минем кем булырга телим?” дигән темага иҗади эш эшләү бирелә. Язып куегыз.
  Укучылар, сез бүгенге дәрестә куйган сорауларга җавап таба алдыгызмы?
- Әйе, бик дөрес.
- Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел, Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел, - дип язган бөек Г.Тукай.
- Укучылар, мин сезнең барыгызның да сәламәт булып, әти-әниләрегезне бары яхшы эш-гамәлләр белән куандыручы, эшчән, тәртипле, юмарт, акыллы һәм бәхетле, заманыбызга кирәкле шәхесләр булып үсеп җитүегезне телим. Дәресебез тәмам. Сезгә зур рәхмәт!

**Галеева Ю.В.**
ГБПОУ «Лубянский лесотехнический колледж»
преподаватель информатики

## СОЗДАНИЕ ОТКРЫТОГО ЭЛЕКТРОННОГО КУРСА ПО ИНФОРМАТИКЕ ДЛЯ СТУДЕНТОВ КОЛЛЕДЖА НА ПЛАТФОРМЕ STEPIK

Современная система образования, как и все информационное общество в целом, претерпевает существенные качественные изменения, обусловленные развитием различных интерактивных технологий и их возрастающим влиянием на все сферы деятельности человека. Реформирование системы среднего профессионального и высшего образования в направлении признания студента центральной фигурой учебного процесса с одновременным развитием его познавательной активности является сегодня обоснованной необходимостью педагогики. Данный процесс предусматривает перестройку процесса обучения, конечной целью которого должны стать максимальное раскрытие индивидуальных возможностей и саморазвитие личности каждого студента [Романова, 2018:5].

Одной из наиболее оптимальных форм современного обучения, в равной степени эффективного при получении основного и дополнительного образования, является дистанционная форма, называемая рядом исследователей образовательной системой 21 века [5, 8, 9]. Именно дистанционная форма обучения дает возможность создания систем массового непрерывного самообучения и общего обмена информацией, наиболее адекватно и гибко реагирует на потребности общества в части подготовки высокопрофессиональных специалистов/

Массовый открытый онлайн-курс — это интернет-ресурс с интерактивным участием и открытым доступом, позволяющий любому желающему изучить тот или иной дисциплинарный курс и сдать экзамен в режиме онлайн. Наиболее разработанными и получившими широкое распространение международными онлайн-курсами сегодня считаются платформы Coursera, Khan Academy, edX, Futurelearn, Open2Study [Лебедева, 2015:105]. Национальная платформа открытого образования, учрежденная ведущими ВУЗами России, с 1 сентября 2015 г. предоставляет пользователю возможность проходить курсы на русском языке по базовым дисциплинам бакалавриата и магистратуры [10]. Также

в образовательном пространстве Российской Федерации можно выделить такие порталы, как «МООК — в образовании» МГУ им. М. В. Ломоносова (проект «Университет без границ»), «Лекториум», «Универсариум», «Arzamas», онлайн-курсы Высшей школы экономики, Московского физико-технического института и Санкт-Петербургского государственного университета и др.

Внедрение онлайн-курса в колледже это инновационный метод образования, который соответствует требованиям и интересом современного студента. Развивает коммуникативные качества, культуру интернет общения, сотрудничество и расширяет образовательное пространство.

Курс разработан на основе рекомендованной ФГАУ «ФИРО» примерной общеобразовательной учебной дисциплиной «Информатика» для профессиональных образовательных учреждений автор М.С. Цветкова. Основная задача курса это структурирование учебного материала, возможность студентам изучить тему и выполнить задания в условиях отсутствия на паре. Сам курс разделен на 6 модулей, в каждый модуль разделен на уроки, содержащие видеоматериал из интернет источников, лекционный материал, тестовые или творческие задания, методические указания к практическим работам, материал к контрольной работе. За счет инструмента дедлайн регулируются сроки предоставления материала, урок открывается за один день до начала аудиторного занятия. Все контрольные и зачет сдается в присутствие преподавателя или в форме прокторинга. Результаты выполнения заданий в бальной системе выводятся в форме отчета в формате * .xlsx, остается только перевести баллы в оценки.

К потенциальным трудностям, с которыми могут столкнуться пользователи онлайн-курсов, можно отнести:

– отсутствие элементарной компьютерной грамотности;

– недостаточную саморегуляцию обучения;

– отсутствие привычек социализации, установления контактов с другими обучающимся;

– трудности оценивания уровня усвоения материала слушателями, которые предполагают документально подтвердить свое обучение для предъявления документа в другие учебные заведения или работодателю;

– потеря ориентации для тех, кто привык к строгим академическим курсам.

Вместе с тем, положительных сторон у онлайн-курсов в условиях стремительного развития информационного общества гораздо больше:

– обучение в неформальных условиях, а не в аудиториях;

– гибкость любого онлайн-курса, что позволяет обучающемуся работать в удобное для него время [Махаметова, 2017:2].

Стремительное развитие таких курсов количественно уменьшает роль традиционной системы образования, однако, не принижает ее фундаментально-академического значения. Несмотря на радикальную трансформацию процесса обучения в условиях массовой информатизации общества, качественное непрерывное образование невозможно без базиса теоретических знаний, полученных с участием педагогов, экспертов, профессионалов той или иной отрасли наук.

## Список литературы


1. Романова Н. Л. Онлайн-курсы как инновационная форма дистанционного обучения // Педагогика высшей школы. — 2018. — №2. — С. 5-8. — URL https://moluch.ru/th/3/archive/86/3178/ (дата обращения: 20.11.2018).
2. Вьюшкина, Е. Г. Массовые открытые онлайн-курсы: теория, история, перспективы использования / Е. Г. Вьюшкина // Известия Саратовского университета. Серия: Философия. Психология. Педагогика. — 2015. — Том 15. — № 2. — С. 78–83.
3. Лебедева, М. Б. Массовые открытые онлайн-курсы как тенденция развития образования / М. Б. Лебедева // Человек и образование. — 2015. — № 1(42). — С. 105–108.
4. Махаметова, М. М. Плюсы и минусы онлайн-обучения / М. М. Махаметова // Современная педагогика. — 2017. — № 5(54). — С. 1–2.

**Галиева А.Ф.**
МБОУ-Арская гимназия №5
Арского муниципалдьного района РТ
учитель английского языка

**УРОК АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКА В 6 КЛАССЕ ПО УЧЕБНИКУ ENGLISH**

**Класс**:6 «А»
Учебник по английскому языку 6 класс English, О.В.Афанасьева, И.В. Михеева
Учебныйраздел :8 “ England”.
**Тип урока**: урок закрепление пройденного материала
**Цели урока:**
- ознакомление с причастием(English Participle);
- тренировка в переводе словосочетаний с причастием;
- актуализация изученной лексики в устной речи.

**Ход урока**

**1. Орг.момент**
T:Good morning, boys and girls! I’m glad to see you!
Who is absent? What date is it today?
What is the weather like today? How are you ? Very good. Now I want you to greet your partner to your face, then with the partner to your shoulder. Give a smile to each other.
I think you are ready to work hard. Sit down , please.
Let’s start our lesson.

T: Today first, you will have a geography quiz. Then I want you to learn how to describe things using special forms of the verbs. After that you will have a practice in making and translating the word combinations and sentences.

**2. Речевая разминка**
Учитель задает вопросы о местоположении стран в Европе.
T: Open your books at page 96 and look at the map. What country is situated to the north of Italy?
P: Austria is.
T: What country is situated to the west of Russia?
P: Sweden is.
T: Where is Ireland situated?
P: It is situated in the north-west of Europe.
T: Where is Spain situated?
P: It is situated in the south-west of Europe.

**3. Проверка домашнего задания (**упр. 6, с. 97)
T: Your home task to choose one country and compare its position with three of four other countries. Have you done it?
Несколько учеников описывают местоположение стран с помощью карты. После этого учитель раздает ученикам карточки, на которых написаны названия трех европейских стран. Учащиеся должны рассказать, где находятся эти страны в Европе и по отношению друг к другу. Например:

**France**
**Italy**
**Germany**

Предполагаемое высказывание ученика:
P: France is in the south-west of Europe. Italy is in the south of Europe. Germany is in the centre of Europe. Germany is to the north of Italy and to the north-east of France. Italy is to the south of Germany and to the south-east of France. France is to the south-west of Germany and to the north-west of Italy.
В это время учащиеся выполняют задания на карточках.

Make the right choice: its or it's
1. The film is famous for … actors.
2. … the most unbelievable thing I've heard.
3. People like to stay at this hotel because of … high-level service.
4. I like this car for … safety.
5. I think … too late to go for a walk.
6. … her book ,not mine.
Keys: 1.its; 2.it's; 3.its;4 .its;5.It's;6.it's

**4. Ознакомление с причастиями (таблица Look, read and remember!,с.98)**

T: We usually use the adjectives to describe things, for example, cold weather, a beautiful girl, and so on. Today I want you to learn how to describe things using special forms of the verbs. Let's read and translate the sentences in the table on page 98.

Ученики читают и переводят предложения с помощью учителя.

T: The words in bold are participles. There are two participles in English:
Participle I and Participle II. We form Participle I with-ing (play-playing).
Participle II consists with the third form of the werb (work-worked, fall-fallen)

Учитель должен объяснить учащимся, что в английском языке существуют причастие 1 (Participle I) и причастие 2 (Participle II), причастие 1 образуется от основы инфинитива путем добавления-ing (ask-asking). Если глагол оканчивается на букву е, то при образовании причастия 1 он утрачивает эту букву (smoke-smoking).Однако если глагол оканчивается на две буквы ee, изменений не происходит (agree-agreeing). У глаголов с одной согласной на конце, перед которой стоит ударная гласная, происходит удвоение конечной согласной (stopping,planning), но если в конце слова находится неударный слог, согласная не удваивается(visiting,listening).

Причастие 1 чаще всего переводится на русский язык с помощью причастий настоящего времени(writing-пишущий, reading-читающий). Причастие 2 совпадает с третьей формой глагола. Она обычно имеет страдательное значение и переводится на русский язык страдательным причастием прошедшего времени. В данном уроке причастие рассматривается только в функции определения.

**5. Тренировка в переводе и употреблении Participle I**

а) Упр. 8, с. 98
T: Read the word combinations in Russian and give English equivalents for them.
Ученики переводят словосочетания и записывают перевод на доске, обращая внимание на орфографию слов.
б) Упр. 9, с. 98
T: Now read the word combinations in English and give their Russian equivalents.
Учащиеся переводят словосочетания на русский язык.
T: Match the two parts of the sentences after the letter B.
Ученики читают получившиеся предложения.
T: I give you a verb and you make up your own word combinations. For example, I say to run, and you say the running boy. Is it clear?
Учитель называет глаголы, ученики образуют от них причастие и придумывают словосочетание, например:
to dance-the dancing girls
to cry-the crying baby
to sing-the singing birds
to clean-the cleaning powder

**6. Повторение форм неправильных глаголов**

T: Do you remember the three forms of the irregular verbs? Let's have a fun. Come here and make a circle, please. I throw the ball and say a verb. You catch the ball and say the second form of the verb and pass the ball to someone. That person says the third form and gives me the ball back.
Buy …
P1. Bought …
P2. Bought.

And now listen to the music,the next task. You must choose one of this paper shirts and move slowly trying to find your partner. There are regular and irregular verbs on these papers. As soon as you find your partner rise your hands.
Дети берут со стола карточки с надписями правильных и неправильных глаголов. Двигаются под музыку ища свою пару. Как только находят, берутся за руки и поднимают их. Так учитель видит готовность учащихся.( Make- made, have-had, meet- met, come-came )

**7. Тренировка в переводе и употреблении Participle II**

а) Упр. 11, с. 99
T: Let's come back to the textbook. Read the word combinations of ex. 11, page 99, and give English equivalents for them.
Ученики переводят словосочетания и записывают перевод на доске.
б) Упр. 12, с. 105
T: Now read the word combinations in English and give their Russian equivalents.
Учащиеся переводят словосочетания на русский язык.
T: Match the two parts of the sentences after the letter B
Ученики читают получившиеся предложения.

**8. Итоги урока**

T: The lesson is over now. Most of you have worked very well. But now I would like to know did you like the lesson? Choose one of these 3 smiles and show me. Thanks a lot for your work. At home you will look through the table on page 98 again do ex. 13. You are to complete the sentences choosing the right participles. Good bye!
Учитель подводит итоги урока и оценивает работу учеников.
Домашнее задание: L8, ex. 13

**Галиева Г.Т.**
Балтач районы, Алан авылы
МБГБУ "Алан башлангыч
мәктәп – балалар бакчасы"
беренче категорияле тәрбияче

## СЕРЛЕ РӘСЕМ

зурлар төркемендә традицион булмаган алым белән
рәсем ясауның план-конспекты

**Максат**: иҗади эшчэнлектә балаларны яңа традицион булмаган алым белән таныштыру- чәнечке белән рәсем ясау.
**Бурычлары**:
1) игътибарлылык, иҗадилык, пөхтәлек күнекмәләре тәрбияләү;
2)иҗади күзаллау һәм уйлау сәләтен үстерү;
3) яңа традицион булмаган алым белән таныштыру - чәнечке белән рәсем ясарга өйрәтү.
**Интеграль белем бирү өлкәләре:** иҗади-эстетик,танып белү,физик үсеш.
**Методик алымнар һәм чаралар:** уен алым, сорау - җавап, мактау, практик эш, бәяләү, физминутка.
**Барышы**:
**Тәрбияче**: балалар, бүген безнең иҗади шөгыль. Без бүген серле рәсем ясыйбыз. Нәрсәсе белән серле соң ул? Ничек уйлыйсыз? (балалар җавабы)
Дөрес, без бүген рәсемне үзебез уйлап ясыйбыз.Фантазияне, уйлап чыгаруны эшкә җигәбез.Үзегезнең өстәлләрегезгә күз салыгыз эле. Рәсем ясау өчен барлык кирәкле әйберләр дә бармы? (балалар җавабы)
**Тәрбияче**: Өстәл өстендә тәртип юк. Әйдәгез, бергәләп тиз генә тәртипләп куйыйк әле. Гуашь, краска, карандашлар , салфетка бар. Ә безнең пумалалар кайда микән?(Тәрбияче пумалалар тора торган шкафны карый)

**Тәрбияче:** Балалар, пумалалар югалган бит безнең. Без хәзер рәсемне нәрсә белән ясыйбыз инде? Әйдәгез бергәләп эзлибез!

(Тәрбияче балалар белән бергәләп эзли. Пумалалар тора торган стаканда чәнечкеләр торганын күреп алалар)

**Тәрбияче**:Тәк-тәк-тәк.Кемдер безнең белән шаярырга уйлаган, безнең пумалаларны чәнечкегә алыштырып куйган. Нишләргә инде безгә?

(балалар җавабы)

**Тәрбияче**: Әйдәгез ,без чәчәкләрне чәнечке белән ясап карыйбыз.Ничек булыр микән?

(балалар җавабы)

**Тәрбияче**: Яхшы.Ләкин чәнечке белән рәсем ясаганчы бармакларыбызны рәсем ясарга әзерләргә кирәк.

**Бармак уены:** Матур рәсем ясар өчен
Бармакларны уйнатыйк.
Менә зуры,уртанчысы,
Атсыз һәм чәнти бармак
Күрсәткечне оныттык
Кәҗә мөгезе ясыйк.
Куян колагын онытмыйк
Бармак белән күрсәтик.

**Тәрбияче:** Әйдәгез экспериментны башлыйбыз.Зур кәгазь битен алыгыз. Пумаланы буяуга ничек тиерсәгез,чәнечкене дә итегез.Ә хәзер дәфтәр битенә туры сызык сызабыз.

(Тәрбияче әлеге эшне тактада күрсәтә,аннан соң балалар дәфтәр битендә эшлиләр).

**Тәрбияче**: Килеп чыгамы? (балалар җавабы)

**Тәрбияче**:Чәнечкеләрегезне сулы стаканда юып алыгыз һәм салфеткалар белән сөртегез.Ә хэзер икенче төс белән дулкынлы сызык үткәрәбез. Буяуларыгыз җитеп бетмәсә чәнечкене тагын берманып алабыз.

(Тәрбияче әлеге эшне тактада күрсәтә,аннан соң балалар дәфтәр битендә эшлиләр).

**Тәрбияче:** Булдырдыгыз, менә без чәнечке белән рәсем ясарга өйрәндек.Ардыгызмы? Әйдәгез хәзер ял итеп алабыз.

Бер-күтәрелдек,күтәрелдек
Ике-бөгелдек,турайдык.
Өч-уч төбен чәбәкләдек
Дүрткә кулларны суздык,
Бишкә кулны болгадык
Алтыга әкрен генә утырдык.

**Тәрбияче:**Әйдәгез,балалар шөгылебезгә кире әйләнеп кайтабыз.Кем хәтерли,без бүген нинди темага рәсем ясыйбыз?

**Балалар җавабы.**

**Тәрбияче**: Дөрес,без бүген серле рәсем ясыйбыз. Ә серле рәсемне без чәнечкеләр ярдәмендә ясыйбыз, шулаймы? Вакытны әрәм итмибез рәсемне ясый башлыйбыз.

(Балалар эшкә керешәләр.Тәрбияче һәр бала янына килә,нинди темага ясаячагын сорый.Авырсынган балаларга әйтеп җибәрә,юнәлеш бирә.Фломастерлар белән рәсемне тулыландырып җибәрергә мөмкин булуын әйтә).

Тәрбияче:Балалар карагыз әле, күпме серле рәсем барлыкка килгән монда! Сез барыгыз да булдырдыгыз. Кем үзенең рәсеме турында сөйләргә тели.

(Балалар чиратлашып үзләренең рәсемнәре турында сөйлиләр.Тәрбияче сораулар биреп балаларга булыша).Шөгыль ахырында тәрбияче балалар белән эшләгән эшкә йомгак ясый.

Тәрбияче: Балалар сезгә яңа пумалалар ошадымы? Нәрсә ошамады? Нәрсәне эшләве авыр булды? Сез чәнечке турында нинди яңалык белдегез? Чәнечке белән тагын рәсем ясар идегезме?

Балалар җавабы.

Тәрбияче: Без бүген сезнең белән традицион булмаган техника-чәнечке белән рәсем ясарга өйрәндек. Хәзер инде без чәнечкенең табак – савыт приборы гына тугел,аның белән тылсымлы картиналар ясап булуын да белдек.

**Галимова Э.Г.**
МБДОУ «Карадуванский детский сад комбинированного вида»
Балтасинского района РТ
воспитатель

**ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ, ОЧКАНДА ШУЛ БУЛЫР**
(ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЕ)

Балалар бакчасы һәм гаилә белән берлектә тату, бәхетле гаилә төзердәй шәхесләр тәрбияләү төп максатларыбызның берсе. Аны тормышка ашыру балалар бакчасының һәм ата-аналарыбызның зур тырышлыкларын таләп итә. Гаилә – баланың төп тәрбиячесе, тотрыклы гаилә традицияләре саклаганда гына балага дөрес тәрбия биреп була. Бала чакта алмаган күнекмәләрне кеше гомере буе да өйрәнә алмаска мөмкин.

Гаилә тәрбиясенең мөһимлеген аңлап бакчабызда һәр гаилә белән тулы бәйләнешле элемтәләр булдырдык. Узара бер-беребезгә ярдәм итеп, тәҗрибә уртаклашып эшлибез. Бала яшәгән өй, мөхит эчендә булган тәрбия үзенчәлекләре белән танышабыз. Әти-әниләрне кызыксындырган сорауларга җаваплар бирәбез, аларның тәкъдимнәре нигезендә тәрбия чараларыбызны планлаштырабыз. Гаилә белемен бирүне эшчәнлеге бакчабызда – уен эшчәнлеге, матур әдәбият, сөйләм үстерү, рәсем, музыка, танып-белү үсеше, физик, театр эшчәнлеге, сәламәтләндерү, бәйрәмнәр, күргәзмәләр, ата-аналар белән максатчан эшләр оештыру юлы белән алып барыла.

Тәрбия чаралары үтемле, аңлаешлы булсын өчен, ата-аналарга педагогик, гаилә белеменбирүне бер эзлеклелектә, бер юнәлештә алып барабыз. Тәрбиячеләр, логопед, шәфкать туташы, читтән чакырылган психолог, табиб, юрист, дин әхелләре тарафыннан лекцияләр укыла. Үз чиратында ата-аналарда үзләренең тәрбия алымнары белән уртаклашалар, үзләре борчыган сорауларга җаваплар эзлиләр.

Видеоконференцияләр үткәрү, ачык ишекләр көне уздыру, атнаның һәр пәнҗешәмбе көнендә “Балам-багалмам” проекты нигезендә ата-аналар белән балаларның уртак шөгыльләре, төркемнәрдә ата-аналар почмагын даими тулыландыру, туган проблемаларны хәл итәргә, гаилә белеменә нигез салырга ярдәм итәләр. ”Әдәп-төбе – матур гадәт” темасы астында гаилә белеме, гаилә тәрбиясенең асылына төшенү өчен, әти-әниләрне бөек мәгърифәтчеләребез Каюм Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдиннең нәсыйхәтләре белән дә таныштырабыз.

Бакчабызда гаиләләр катнашында үткәрелгән кичәләр, очрашулар, бәйрәмнәр дә гаиләдә татулык, миһербанлык, олылау, әти-әнигә хөрмәт, ихтирам хисе тәрбияли, тату гаилә рәхәтен тоярга ярдәм итә. Бу очрашуларда катнашу баланың сәләтен, хәрәкәт активлыгың, танып-белү активлыгын үстерә, сүзлек хәзинәсен баета. Бигрәк тә “Безнең гаилә-тату гаилә”, “Балагызның исеме нәрсәне аңлата”, “Кем-кемгә туган”, “Балагыз белән булган кызыклы хәлләр”, “Иң матур сүзле гаилә”, “Гаилә җырлары”, “Шигырь бәйрәмнәре”, һәм башка багышланган кичәләребез бу исәптән оттырышсыз дип уйлыйм.

Гаилә тәрбиясенә багышлап үткәрелгән күргәзмәләребез балалар өчен дә, әти-әниләр өчен дә бик җанлы үтәләр. “Әти-әни һөнәре”, “Әтием солдат булган”, “Гаиләбездән - кошларга бүләк”, “Гаиләбезнең иң олы кешеләре” кебек күргәзмәләребез аша балаларыбыз әти-әнисенең шәхси үрнәгендә туган илгә, туган телгә, хезмәткә, гаиләдәге һәр шәхескә мәхәббәтнең мөһимлеген аңлый. Аларның игътибарга лаек сыйфатлары белән горурланалар.

Әти-әниләренең эш урыннарына даими экскурсияләр оештыруыбыз да, балаларыбызның әти-әни хезмәтенең мөһимлеген аңлап, аларның һөнәрләре турында белемнәре арта. Гаиләдә ата-ана балалар белән бергә, алар көченнән килгән эшләр белән шөгыльләнүләрен күзәтеп, сораштырып, хуплап торабыз. Чөнки хезмәт белән бергә ихтыяр, көче дә тәрбияләнә. Бакчабызда халкыбыз йолалары, гореф-гадәтләребезне чагылдырган,

гаиләләр ярдәме белән бергә үткәрелүче “Әбием сандыгы”, “Шәҗәрә бәйрәме”, “Калфак чигү”, “Әниләрнең балачак уеннары”, “Әниемнең балачак курчаклары” һәм башка кичәләр балаларның аңына, рухына әдәплелек үрнәкләрен сеңдерү, хезмәт тәрбиясе бирү, халкыбыз һәм нәсел хәзинәләрен дәвам итүнең иң асыл юлы дип уйлыйм. Гаилә шәҗәрәсе балага туганлык бәйләнешләре турында мәгълүмат бирә. Ул гаилә төшенчәсен аңлый, гаиләсенең килеп чыгу тарихы белән таныша, аларга карата хөрмәт, кайгырту теләге тәрбияли.

Сугыш һәм хезмәт ветераннарын бакчабызга чакыру, яисә бәйрәмнәрдә балалар белән аларның өйләренә барып котлау да матур традициябез. Әби-бабайларының, туганнарының җәмгыять тормышында тоткан урыннары, батырлыклары, һөнәрләре белән танышу аша балаларыбызда горурлык, ихтирам хисе, кайгыртучанлык хисе, узара ярдәмләшү теләге тәрбиялибез.

Бакчага килгәч балаларыбызның өйдә вакытларын ничек уздырулары белән көндәлек кызыксынып торабыз. Яшьләренә карата балалар өчен әти –әниләргә уеннар, матур әдәбият исемлеге, кул эшләре белән шөгыльләнү буенча киңәш-тәкъдимнәр бирәбез. Районкүләм, Республикакүләм ярышларда катнашучы гаиләләргә һәрьяклап ярдәм итәбез.

Табигатькә мәрхәмәтлелек мөнәсәбәте тәрбияләүгә ирешү, аның белән танышу өчен, тәрбиячеләребез ата-аналар белән берлектә үзебезнең тирәдәге каенлыкка, чишмә буена, болынлыкка, Бакый күленә экскурсияләр оештырабыз, туган авылыбызда яшәүче авылдашларыбызның көн-күреше белән таныштырабыз.

Гаилә белән балалар бакчасы - балалар сәламәтлеген саклау, ныгыту өчен бер юнәлештә бердәм эш алып бара. Өй мохитендә көн тәртибен төгәл үтәүне, бакчада үткәрелүче чыныктыру чараларын өйдә үткәрүне һәрьяклап күзәтү астында тотабыз.

Бакчабызда үтүче “Спорт атналыгы”, “Әти-әни – мин спорт гаиләсе”, “Сабан туй”, гигиена күнекмәләренә багышланган ярыш –кичәләр гаиләне берләштерергә, сәламәтлеккә игътибарлы булырга өйрәтәләр. Тәрбиячеләребез, әти-әниләр соравы буенча , ял, бәйрәм көннәрендә чаңгы, чана, хоккей уеннарын оештыралар, ахырда матур итеп бергәләп эссе чәй, коймаклар белән сыйланалар.

15 нче майда Халыкара гаилә көнендә ата-аналарыбыз балалар белән бергәләп концерт номерлары әзерлиләр, курчак театры, спектакльләре куябыз. “Гаилә турында балалар рәсеме” дигән зур күргәзмә оештырабыз. Гаиләдә кеше үзен бәхетле тоя, һәрьяклап тәрбия ала, сәләте ачыла, үсә. Гаиләдәге кеше – бәхетле кеше, балалар гаиләгә ышанып, гаилә көчен тоеп, гаилә кыйммәтләрен аңга сеңдереп, лаеклы шәхес булып үсәләр.

**Задание № 2.**
**5 баллов – нет ошибок**
**4 балла – 1-2 ошибки**
**3 балла – 3-4 ошибки**
**2 балла – более 5 ошибок**
**Задание № 3.**

**Базовый уровень.**
**2 балла – нет ошибок**
**1 балл – есть ошибки**

**Повышенный уровень.**
**4 балла – нет ошибок**
**3 балла - 1-2 ошибки**
**2 балла – 3-4 ошибки**
**1 балл – более 4 ошибок**

**Высокий уровень.**
**6 баллов – нет ошибок**
**5 баллов – 1 ошибка**
**4 балла – 2-3 ошибки**
**3 балла – 4 ошибки**
**2 балла – более 4 ошибок**

**Итоговый балл:**

| **Оценка** | **5** | **4** | **3** |
|---|---|---|---|
| **Количество баллов** | **17-19** | **12-16** | **9-11** |

**Җамалиева А.М.**
Арча районы Яңа Кишет төп гомуми белем мәктәбе
югары квалификационлы татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕН ӨЙРӘНӘБЕЗ
### (морфология буенча күнегүләр җыентыгы)
### Кереш

6 нчы сыйныфта программа морфология бүлеген тулысынча өйрәнүне күздә тотып төзелгән. Темалар үткәндә, укучыларның белемнәрен тикшергәндә, сүз төркемнәрен кабатлаганда файдалану максатыннан “Туган телдән күнегүләр җыентыгы” төзелде. Җыентыкта бирелгән текстлар аша белемнәрне ныгыту, районыбыз, аның әдәбият-сәнгать әһелләре, күренекле кешеләре турында мәгълүмат бирү, якташ язучылар иҗатының гомумтатар әдәбияты тарихында тоткан урынын билгеләү, аларның әсәрләре белән танышу, иҗатларына, туган төбәгебезгә ихтирам хисе тәрбияләү күздә тотыла.

**Исем сүз төркеме.**

**1 нче күнегү. Тартым белән төрләнгән исемнәрнең зат-санын, килешен билгеләргә.**

Үзе ятимлекне кичермәгән, гомере буена әни җылысын, аның даими ярдәмен тоеп яшәгән кеше ана дигән бөек затның чын кадерен дә, аның асылын да беркайчан да белеп бетерә алмыйдыр. Әни бит әле ул авыр минутларыңда син килеп сыена алган, назлы куллары белән битеңнән сыйпап сине юаткан, күңелеңне тапкан бер шәфкать иясе генә түгел. Ул синең вакытында тамагыңны туйдыручы, өс-башыңны караучы, ертылса ямап , керләнсә юып кидерүче, сине үстереп, гакыл һәм хәер-фатиха биреп, олы тормыш юлына чыгарып җибәрүче. Җыеп кына әйткәндә, ул сине бу дөньяда яшәтүче! Карагыз сез, ошбу Җиһанда адәм баласы гына түгел, ә төрле җанварлар , терлекләр, кош-кортлар - барчасы, барчасы да ана ярдәменә таяна. Әгәр аннан мәхрүм кала икән, зур авырлыклар кичерә, хәтта һәлак булырга да мөмкин.

(Р.Фәизов)

**2 нче күнегү. Ялгызлык исемнәрне табып, асларына сызарга.**

Арча районы – борынгы болгар бабаларыбыз гомер иткән, гүзәл табигатьле, табыннарыбызны мең төрле сый-нигъмәтләр белән баетучы алтын куллы эшчеләрне, татар халкының әдәбиятын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен үстерүгә зур өлеш керткән бөек Тукайны, Мәрҗанине һәм башка искиткеч олы шәхесләрне үстергән тарихи төбәк...

Арча районы авыл хуҗалыгы өлкәсендә дә нәтиҗәле эшли, елдан-ел матур күрсәткечләргә ирешә, ил табынын баетуга саллы өлеш кертә. Халыкның тырыш хезмәте нәтиҗәсендә, район танымаслык булып үзгәрә, көннән-көн матурая, төзекләнә.

(М.Ш.Шәймиев ”Бөек Тукай Ватаны син, Арча” китабыннан)

**3 нче күнегү**. **Текстны укырга, ялгызлык исемнәрен табарга.**

Арча районы – Татарстанның иң зур районнарының берсе. Ул җөмһүриятебезнең төньяк-көнбатышына урнашкан һәм Мари Республикасы, Биектау, Питрәч, Балтач, Саба, Әтнә районнары белән чикләшә. Анда зур тимер юл станциясе бар, башкалабыз Казанга кадәр үзәктән 60 чакрым.

Безнең яктан татарның атаклы галимнәре Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Шәмсетдин Күлтәси һәм башкалар үсеп чыккан. Атаклы шагыйрь һәм язучылар Габдулла Тукай, Мәхмүт Галәү, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Рафаэль Төхфәтуллин һәм башка бик күпләрнең исемнәре яхшы мәгълүм. Атаклы драматург Галиәсгар Камалның балачагы безнең районда узган. Барыбызга да таныш җырчы Федор Шаляпин 1895 елда Арчада училищеда укыган.

(“Арча төбәге тарихы” китабыннан)

**4 нче күнегү. Күп ноктaлар урынына тиешле килеш кушымчалары куеп язарга.**

...Кырларың... үтәм сөенә-сөенә,
Камыллар... хәтта иркәли.
Оныталмам, авыл..., оныталмам
Сызылып аткан һәр таң- иртәң...!
Оныталмам сихри кичләрең...,
Сайрар кошларың.... моңнар...
Кайда гына булсам да мин, авыл... ,
Сине уйлап, сагынып җырлармын!
Табалмадым синнән матур урын,
Күпме эзләсәм дә, Миржәм...!
Көч-дәрт бирәсең син һәр бала... ,
И Миржәм... минем - җир яме!

(Р.Җамал)

**Сыйфат сүз төркеме.**

**5 нче күнегү. Текстны күчереп язарга, сыйфатларның астына сызарга.**

Тукай үзен тулысынча халыкка хезмәткә багышлады. Халык язмышын, халык мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәү аның өчен бар нәрсәдән дә югарырак иде. .. Ул халыкның көченә, аның матур һәм якты киләчәгенә ышанычын бервакытта да җуймый. Аныңча, татар кешесе, һичшиксез, канатларын киң җилпеп, кимсетү һәм түбәнлекләрдән югары күтәреләчәк, үз язмышын үзе хәл итә башлаячак. Моңарга ышаныч аның:”Халык зур ул,

көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул, әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә, бу күренештә йөри...”- кебек мәгълүм сүзләреннән дә ачык күренеп тора. Тукайны , халык өстенә төшкән кыенлыклар, җәбер-золым, авыр язмыш хакында гына җырлаудан арынып, туган як табигате, анда яшәүче кешеләрнең матурлыгы һәм рухи байлыгына соклану да иҗат итәргә рухландыра.

(”Бөек Тукай Ватаны син,Арча”китабыннан)

**6 нчы күнегү. Бирелгән тексттан асыл һәм нисби сыйфатларны аерып күрсәтергә.**

Герман профессоры Готһольд Вайль әсирләр арасында татар җырларын язып йөрде. Шәйхи солдат монда да кирәкле кеше булып чыкты. Ул мәдрәсәдә ятлаган «Тәндә җаным»ны профессорга җырлап күрсәтте. Профессор боларны җыеп китап чыгарачагын тылмач аркылы сөйләде. Апрель аенда Вюнс-дорф кырында алар Сабантуй да ясадылар. Шәйхи солдат шул вакытта Кара Чыршы авылында беркем дә күрмәгән һәм күрмәячәк хәлләрнең шаһиты булды. Сабантуйда алар татарча көрәш, капчык сугышы кебек милли уеннарны күрсәттеләр. Аннан герман атларын җигеп җир сөрделәр, ат җитмәгән сабаннарга үзләре җигелеп йөрделәр, тубал белән орлык чәчеп күрсәттеләр. Шәйхи солдат җир буенча беренче булып барды, тубалдагы бодайны «бисмилла» әйтеп герман җиренә чәчте... Германның кара-көлсу туфрагына бодай бөртекләре белән тавык йомыркасы сипте. Татар йоласы! Орлыклар шулай эре булсын!

(М. Мәһдиев “Без кырык беренче ел балалары”)

**7 нче күнегү. Тексттагы сыйфатларның дәрәҗәсен билгеләргә.**

Ул вакытта инде апай да, эшләрен бетереп, шул ук лампа яктысына килә. Ул, киергесенең бер башын сәкегә куйган да икенче башын тез өсләренә җайлап, алсу төсле ситсыга чынаяк өстеме, нәрсәме чигәргә тотына. Көндез тәрәзә янында минем аның шул алсу чүпрәккә карандаш белән тырышып-тырышып чәчәк бизәкләре төшергәнен карап торганым бар. Менә хәзер апай, тамбур энәләрен шул карандаш эзләреннән йөртеп, дебеттән яшел, зәңгәр, шәмәхә төсле чәчәкләр чигә. Апайның кечкенә генә коңгырт бармаклары, бик килешле булып, тегеләй дә болай уйнап кына тора, энәләре бер батырган саен шарт та шорт килә, бармагындагы көмеш балдагы, очкын чәчрәткәндәй, җелт-җелт итә. Күзләре озын кара керфекләре астында бөтенләй йомылып беткән шикелле. Чебен эзләре шикелле генә шул нечкә юлларны ничек күрә икән соң ул? Дебетенең күзәнәкләре ничек төшеп калмый да ничек чәчәген бозып җибәрми икән?

(Г. Бәширов “Туган ягым яшел бишек”)

**Рәвеш сүз төркеме.**

**8 нче күнегү. Рәвешләргә сызарга, калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә морфологик анализ ясарга.**

Ул яз көне, башын да күтәрмичә, айлар буе киндерләр, чүпләмле сөлгеләр суга, кыш буе намазлыклар, өстәл япкычлары, кулъяулыклар чигә, һәммәбезгә дә пирчәткәләр, оекбашлар бәйләп бирә. Мин аны, **азрак** усал булса да, кызганып куям. Иптәш кызлары күрше авылларга утырмага барганда, аулак өйләргә йөргәндә, менә шулай бер ирек ачмыйча, бөкресен чыгарып, көне-төне чигү чигеп утыру бик туйдыргандыр шикелле тоела башлый. Кайчакларда әни дә әйтә:

— Утырма көн-төн чүпләнеп! Күзеңне бетерерсең, сукыр калырсың!—ди.

Апай киергесенә иелгән килеш бераз шулай чигеп утыра да, бөкрәеп килгән аркасын турайтып, әнигә карап ала.

— Үзең сандык малын **мулрак** хәстәрләргә кушасың ич. Өсбашка да кирәк.

— Хәере белән игеннәр уңып китсә...

— Ул ике имананың игене ни дә, үзе ни! Сатарга түгел, ашарга да такы-токы гына.

— Шулай инде. Өй тулы иманасыз да җирсез.

— Шул шул менә. Барысына да әти ничек җиткерсен? Үзең беләсең ич...

Әни белә инде ул, белә. Икмәк салган саен әти аның колагына тукып кына тора:

— Эре иләктән илә онны, күп тотма! Безнең өйдә әти белән абыйның гына җире бар. Хатын кешеләргә җир бирмиләр, ә мин, җир өләшкәч туганлыктан, бөтенләй җирсез калганмын. Җирсез-иманасыз. Әти миңа карап **авыр** сулап алгалый. Бәлки, иманасыз булганга кызгануыдыр? Иманасыз...

(Г. Бәширов “Туган ягым яшел бишек”)

**9 нчы күнегү. Рәвеш төркемчәләрен билгеләргә.**

Абый әллә кайчан ук әзер иде инде. Ул катыргы тышлы бер-ике калын китапны янына куйган да кыяр-кыймас кына әтигә карап алгалый. Әти нәрсә укырга куша бит. Бәлки, ул аңа мәдрәсәдә укыган сабагын тыңлатыр, я, бәлкем, мулла абзыйлар шикелле, кычкырып Коръән укырга кушар. Каян беләсең... Бу юлы әти аңа китапның зәңгәр тышлысын укырга кушты. Әни лампаның филтәсен күтәрә төште, яулыгын артка чөеп бәйләде дә колак тирәсендәге чәч бөртекләрен арткарак сыпырып җибәрде. Нәрсә укуларын аңламасам да, мондый кичәләр миңа бик күңелле тоела иде. Тышта суык, өй бүрәнәләре шарт та шорт килә. Ә без менә шулай, бәйрәм алды кичәсе итеп, җылы өйдә, якты лампа тирәсендә рәхәтләнеп китап укып утырабыз.

(Г. Бәширов “Туган ягым яшел бишек”)

**Фигыль сүз төркеме.**

**10 нчы күнегү. Тексттан фигыльләрне табып, төркемчәләргә аерып язарга.**

Әнинең мичкә төшкән күләгәсен карап утыру китап тыңлауга караганда да кызыграк. Әни үзе мич стенасында әллә нинди озын муенлы сәер хайванга атланган бик дәү кеше булып күренә. Аның тәкә башы хәтле орчыгы, үзеннән-үзе айкалып-чайкалып, әле ишеккә таба атыла, әле сәкегә таба. Утыра торгач, ул шәүләләр бер дә чын түгелдер, әллә нинди күз буяудыр, я әкияттәге кебек тылсымдыр дип уйлый башлыйсың. Утыра торгач, абыйның көйләп-көйләп китап укуы яңадан колакка килеп керә. Ул, аз гына атына биреп, укый да укый. Өй эченә моңарчы ишетелмәгән әллә нинди сәп-сәер ят сүзләр сибелә башлый. Дәгел дип куя, булгай ди, сүз арасында һөд-һөд, дел-дөл, аргамак, фиргавен дип җибәрә, тагын әлләниләр тезеп китә.

(Г. Бәширов “Туган ягым яшел бишек”)

**11 нче күнегү. Текстны күчереп язарга, затланышлы фигыльләрнең астына сызарга.**

Югары очка да килгән кунак кыз, түбән очка да. Әти Казанга солы белән киткәч, безгә дә килеп төште. Ник дисәң, гадәте шулай. Көз ахырында аның үзенең бик сөйкемле бер вакыты бар. Атналар буе вак иләктән иләгәндәй, төтәсләп торып үзәккә үткән, кибәннәрнең янтауларына яшел ямаулыклар үстергән бетмәс-төкәнмәс көзге яңгырлар туктаган. Әниләр елмаюы кебек ягымлы җылы көннәре, көмеш тоҗымнары, салкын төннәре белән әбиләр чуагы да узып киткән. Төнлә белән өй түбәләренә, капка башларына—бөтен җиргә җем-җем иткән ап-ак кырау төшә, агачларга бәс бәйләнә. Көзге пычракта бозылып калган урамнар, юллар, бөтен казылмалары, кисенте һәм чокырлары белән бер төн эчендә шакыраеп каталар. Урамнан узган арбаның дөбердәве бөтен авылны яңгырата. Бөтен дөнья боеккан. Келәт кәрнизендә, кызыл тәпиләрен корсак асларына яшереп, күгәрченнәр бөрешеп утыра. Агач ботакларындагы кабарынкы йонлы мескен чыпчыклар төшенке тавыш белән:

— Суык-суык, суык-суык!—дип зарланалар.

Менә тагын берәр атна уза. Кояш көн саен соңгарак калып чыга башлый. Югарырак күтәрелергә иренеп, түбәннән генә әйләнә дә тизрәк төшеп китәргә ашыга. Көннәр тогын да суытарак төшеп, инешләргә боз ката. Картлар, бишмәт өстеннән билләрен буып, бияләй кияләр дә, озын таякларга таянып, уҗым басуына чыгып керәләр.

(Г. Бәширов “Туган ягым яшел бишек”)

**12 нче күнегү. Фигыльләрнең заман формасын билгеләргә.**

Әле берәр ай гына элек Әбүгалисина белән ничек җенләнгән булсам, хәзер шулай ук, алны-ялны белмичә, тоташтан Тукай шигырьләрен укый башладым. Аның сүзләре нәкъ кирәк вакытында, күктән иңгән кебек, ничектер, үзеннән-үзе күңелгә килеп керә башлады. Әллә ничек кенә искә килә дә, яраткан җыруың шикелле, үзеннән-үзе көйләнә. Күбәләк яисә карлыгач күзгә чалындымы, аның шигырьләре искә төшә. Берәр агайның сука артыннан икегә бөгелеп атлавын күрдеңме, тагын аның шигырен хәтерлисең. Үзебезнең бакча башына я тыкрыкка чыккач, авыл өстенә, чишмәләргә күз төштеме, тагын аның шигырьләре телгә килә.

(Г. Бәширов “Туган ягым яшел бишек”)

**13 нче күнегү. Фигыль юнәлешләрен билгеләргә.**

Зәй буендагы ялгыз шомырт төбенә палаткабызны корып, бер җәйне бик күңелле ял иткән идек без. Мин кармак салып утырам, улым чикерткәләр куа, зәңгәр-кызыл тубын чөеп уйный, кошлар белән сөйләшә, арыгач, шомыртның күләгәсенә ятып йоклый. Шул көннәрдән бирле шомырт якын дустыбызга әйләнде, һәм без улым белән һәр яз шомыртыбызның хәлен белергә бара торган булдык. Шомырт безне бик куанып каршылый, нәни яфраклы ботакларын селкетеп, сәлам бирә. Аннары без шомыртыбыз янына аның шау чәчәккә төренер вакытын чамалап киләбез. Бу вакытта чияләр, алмагачлар, миләшләр үзләренең чәчәк бөреләрен ачар-ачмас кына утыралар. Бу дөньяда үзләре генә белә торган тантана көннәрен көтәләр алар. Җәй азакларына таба да без шомыртыбызга кунакка киләбез. Дустыбыз безне, авызны бераз бөрештерсә дә, бик тәмле чем-кара җимешләре белән сыйлый. Быел шомыртыбызның яфрак ярган шатлыгын уртаклашырга бара алмадык. Шунлыктан аның мул чәчәкле хуш исле бәйрәменә вакытында барып җитәргә ашыктык. Шатлыгын уртаклашырга дип килсәк тә, шомыртның бик моңаеп утырганын күрдек без. Дустыбызның бәйрәменә соңга калдыкмы? Әнә бит, инде чәчәк таҗларын коеп бетерә язган ул.

(Р. Төхфәтуллин “Шомырт нигә елый?”)

**Сан сүз төркеме.**

**14 нче күнегү. Сан төркемчәләрен билгеләргә.**

Ике дус шул ниятне тормышка ашырырга да кереште. Иң уңайлы вакытны көтеп, тавышсыз-нисез генә мәктәпкә шылдылар. Икенче катта шау-шу ишетеп, шунда менделәр. Анда линейка бара икән. Берсен-берсе бүлеп кычкырган тавышлар ишетеп, алар якынрак елышты. Директор, завуч һәм укытучылар – барысы да бишенче сыйныфта укучы Фаязның абыйсы Саматны, Илнурның абыйсы Ильярны дәрескә йөрмәгәннәре, икеле алганнары һәм тәртипсез булганнары өчен пыр туздырып сүгә иде. Абыйларының башлары түбән иелгән, йөзләре кып-кызыл, күзләре өметсез. Моны күреп, Фаяз белән Илнурның котлары очты:
“Монда тагын да начаррак икән! – диде Фаяз.
– Ычкыныйк яхшы чакта, – дип өстәде Илнур.
Алар тиз генә бакчаларына элдерттеләр һәм мыштым гына инде төшләренә керә башлаган, керфекләрен йому белән күз алдына килеп баскан газиз, якын почмакларына барып бастылар…

(Р. Галиуллин “ Яраткан почмак”)

**Алмашлык сүз төркеме.**

**15 нче күнегү. Алмашлык төркемчәләрен билгеләргә.**

Ниһаять, ул көн килеп җитте: соңгы кыңгырау бәйрәме тәмамланды, укучылар өйләренә таралышты. Айдарның кәефе май кояшыныкы кебек якты, күтәренке иде. Шулай булмыйни: өч ай мәктәпкә бармаячак, эти-әнисе эштә чакта берүзе өйдә торачак бит ул! Көне буе туйганчы планшетта уйнаячак, аскы каттагы Марат белән интернеттан футболда көч сынашачак, бер-берсенең шәһәренә яу белән киләчәкләр, боксчылар булып сугышачаклар! Эх, алда нинди күңелле көннәр көтә аны!
− Улым, көн-төн шул планшетыңда уйнап сукыр каласың бит инде! – дип әнисе дә бәйләнмәячәк. Әтисеннән дә:
− Ун яшеңдә үк бөкреләрең чыкты инде, без синең шикелле вакытта урамнан кайтып керми идек, − ише сүзләрне ишетмәячәк.

(Р. Галиуллин “Премия”)

**Йомгаклау**

Мин, татар теле һәм әдәбияты укытучы буларак, үз бурычымны укучыларга ана телен өйрәтү, туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләү белән беррәттән, рухи яктан бай, милли үзаңлы, ватанпәрвар укучылар тәрбияләүдә дә күрәм. Ризаэддин Фәхреддиннең «Укытучының шундые булыр, алтын булачак бер шәкертне туфрак итеп җирдә калдырыр. Укытучының тагын шундые да булыр, туфрак булачак бер баланы алтын итә белер» дигән сүзләрендә күпме хаклык бар. Чыннан да, укытучының төпле белемгә ия булуы, аны дөрес итеп җиткерә белүе бик мөһим.

**Заһидуллина Э.Р.**
Байлар Сабасы бистәсе гимназиясенең
башлангыч сыйныфлар укытучысы

## СҮЗ ТӨЗЕЛЕШЕ ҺӘМ СҮЗ ЯСАЛЫШЫ

Ана теле дәресенә тестлар (3 класс)

1. Тамыр һәм ясагыч кушымчадан торган сүзне тап.
а) он
б) эшче
в) бакчага
г) аккош
2. Тамыр һәм мөнәсәбәт белдерүче кушымчадан торган сүзне тап.
а) дәреслек
б) такта
в) кешене
г) кибетче
3. Тамырдан гына торган сүзне тап.
а) кисүче
б) йорт
в) бәйрәмдә
г) укучы
4. Керпе сүзенә түбәндәге кушымчаларның кайсысын ялгарга кирәк?
а) –дан
б)- дән
в)- тан
г) –тән
5. Түбәндәге сүзләрнең кайсысы кушма сүз?
а) аккош
б) ата-ана
в) сазлык
г) урам
6. Түбәндәге сүзләрнең кайсысы парлы сүз?
а) аккош
б) ата-ана
в) сазлык
г) урам
7. Өй сүзенә түбәндәге кушымчаларның кайсысын ялгарга кирәк?
а) –да
б) –дә
в) –та
г) –тә

**Сүз төркемнәре**

**Исем**

1. Исемгә туры килгән билгеләмәне күрсәт.
а). Предметны белдерә
б) Предметның билгесен белдерә
в) Предметның эшнен, хәрәкәтен белдерә.
2. Исем нинди сорауларга җавап бирә?
а) Ничә? Ничәнче? Күпме?
б) Нинди? Кайсы?
в) Кем? Нәрсә?
г) Нишли? Нишләде? Нишләгән?

3. Күл  сүзенә кайсы күплек кушымчасын ялгарга?
а) -лар
б) -ләр
в) -нар
г) -нәр
4. Ялгызлык исемне билгелә.
а)  сатучы
б) байрак
в) бозау
г) Йолдызкай
5. Уртаклык исемне билгелә.
а)  Булат
б) Арча
в) сандык
г) Кесмәс
6. Иялек килешендәге исемне билгелә.
а) җизнигә
б) Дәреснең
в) тартмада
7. Юнәлеш килешендәге исемне билгелә.
а)  Мәктәпнең
б ) Сазны
в)  Клубта
г) Укытучыга
8. Чыгыш килешендәге исемне билгелә.
а) Күзгә
б) Ишектән
в) Әтинең
г) Өндә
9. Төшем килешендәге исемне билгелә.
а) Телне
б) Илдән
в) Баланнан
г) Шкаф
10. Урын- вакыт килешендәге исемне билгелә.
а) Койманың
б) Таугa
в) Иртәдән
г) Машинада
11. Сыерчык сүзенә кайсы күплек кушымчасын ялгарга?
а) -нар
б) -нәр
в) -лар
г) -ләр
12. Шәл  сүзенә кайсы күплек кушымчасын ялгарга?
а) -нар
б) -нәр
в) -лар
г) -ләр
13. Кыр сүзенә кайсы күплек кушымчасын ялгарга?
а) -нар
б) -нәр
в) -лар
г) -ләр
14. Күбәләк  сүзенә кайсы күплек кушымчасын ялгарга?

а) -нар
б) -нәр
в) -лар
г) -ләр

**Сыйфат**

1. Сыйфатка туры килгән билгеләмәне күрсәт.
а) Предметның билгесен белдерә
б) Предметның эшнен, хәрәкәтен белдерә.
в) Төрле сүз төркемнәрен алмаштырып килә
г) Предметның санын белдерә
2. Сыйфат нинди сорауларга җавап бирә?
а) Кем? Нәрсә?
б) Нинди? Кайсы?
в) Ничә? Ничәнче? Күпме?
г) Нишли? Нишләде? Нишләгән?
3. Матур сыйфатының антонимын тап.
а) Чибәр
б) Күркәм
в) Ямьсез
г) Гүзәл
4. Җылы сыйфатының синонимын тап.
а) Эссе
б) Суык
в) Кызу
г) Салкын

**Фигыль**

1. Фигыльгә туры килгән билгеләмәне күрсәт.
а) Предметның билгесен белдерә
б) Төрле сүз төркемнәрен алмаштырып килә
в) Предметның эшнен, хәрәкәтен белдерә.
г) Предметның санын белдерә
2. Фигыль нинди сорауларга җавап бирә?
а) Ничә? Ничәнче? Күпме?
б) Нинди? Кайсы?
в) Кем? Нәрсә?
г) Нишли? Нишләде? Нишләгән?
3. Саный фигыленең юклык төре нинди кушымчалар ялганып ясала?
а) -ма
б) мә
в) -мый
г) -ми
4. Җыладым фигыле нинди заманда?
а) Хәзерге заман
б) Үткән заман
в) Киләчәк заман
5. Йөгерәбез фигыле ничәнче затта?
а) I зат
б) II зат
в) III зат

**Алмашлык**

1. Алмашлыкка туры килгән билгеләмәне күрсәт.
а) Предметны белдерә
б) Төрле сүз төркемнәрен алмаштырып килә
в) Предметның эшнен, хәрәкәтен белдерә.
2. 3 зат алмашлыкларын күрсәт.

а) Син, сез
б) Мин, без
в) Ул, алар
3. Сез ничә китап алдыгыз? Бу җөмләдә алмашлыкны тап, затын билгелә.
а) 1-зат
б) 2-зат
в) 3-зат

**Сан**

1. Санга туры килгән билгеләмәне күрсәт.
а) Предметның эшнен, хәрәкәтен белдерә.
б) Предметның санын белдерә
в) Төрле сүз төркемнәрен алмаштырып килә
г) Предметның билгесен белдерә
2. Сан нинди сорауларга җавап бирә?
а) Кем? Нәрсә?
б) Ничә? Ничәнче? Күпме?
в) Нинди? Кайсы?
г) Нишли? Нишләде? Нишләгән?
3. Ундүрт нинди сан?
а) Тамыр
б) Кушма
в) Тезмә сан
4. Дүрт нинди сан?
а) Тамыр
б) Кушма
в) Тезмә сан
5. Егерме дүрт нинди сан?
а) Тамыр
б) Кушма
в) Тезмә Сан

**Загриева Г.М., Мусина Ч.Р.**
МБОУ «Казанбашская ООШ» Арского муниципального района РТ
учителя высшей категории

## СТЕПЕНЬ БЛИЗОСТИ АНГЛИЙСКОГО И РУССКОГО ЯЗЫКОВ

В последние годы в олимпиадных работах встречается задание, связанное с сопоставлением русского языка с другими языками на предмет сходства и расхождения. В связи с этим, целью нашей статьи стало выявление степени близости английского и русского языков.

**Анализ лексического строя**. Cherry – черешня, beat—бить, shock -шок, force-форсить. Некоторые слова английского и русского языков очень похожи по звучанию, написанию и имеют общее значение. Возникает вопрос: «Почему они так похожи?» Обратившись к англо-русскому словарю, можно увидеть, что таких слов очень много, а отличаются они окончанием или суффиксом, присущим данному языку. Например, knit - нитки, band - банда, sheet -щит, table - таблица, mooch - мучиться, sedate - седеть.

Известно, что существуют такие группы языков, родство в пределах которых имеет ощутимое практическое значение. Знание одного языка в группе даёт возможность частично понимать и другие. Сравнивая устойчивые слои лексики этих языков, мы можем найти пары слов, не только имеющих общее происхождение, но и в какой-то степени

сохранивших сходный фонетический облик. Например, three – три, my – мой, brother – брат, nose – нос, sun – солнце.

Предлагаем проанализировать ряд созвучных слов, обращая внимания на их смысловую нагрузку. Так, очки переводятся на английский как glasses. Слово очень похоже на русское «глаза». Бесспорно, прослеживается родство языков, ведь очки представляют собой вторые глаза. Что касается созвучия слов, то в близкородственных европейских языках это не диво. Возьмем для примера пару слов money - деньги. Английское слово money является понятным всем. Но мало кто знает, что оно имеет славянские корни и происходит от слова мены, то есть «то, на что меняют». Еще один пример - древнейший русско-славянский корень лан, обозначающий земля, территория. Он встречается в слове Руссолания, т.е. Земля Руссов. В английском языке тоже есть этот корень land - земля, переводим England – выходит Земля Англов. Каковы же основные пути появления общих слов в русском и английском языках? Во-первых, общность между лексическими свойствами русского и английского языков задаётся их общей принадлежностью к индоевропейской семье, поэтому во многих словах обоих языков встречаются корни из их общего древнего праязыка. Эти слова не были заимствованы, они изначально общие. О былой языковой общности и родстве русского и английского языков напоминают множество созвучий среди самых важных слов языка. Среди них: cheek – щека, water –вода, milk – молоко, sister – сестра, salt – соль, day – день, daughter – дочь, cat – кот. Во-вторых, большое количество общих русских и английских слов образовано от латинских корней. Известно, что в средние века латынь была международным языком ученых, через нее во все европейские языки перешло огромное количество слов, которые стали международными: куб - cube, квадрат - quadrate, сфера - sphere, эллипс – ellipse, антибиотик - antibiotic, бактериофаг – bacteriophage и т.д.

И в последнее время русский язык испытывает большой приток новых английских слов. Для описания новых понятий потребовались новые слова, и многие из них приходят из английского. Этому способствует и английская терминология в компьютерной области.

**Анализ грамматического строя.** Английский язык в значительной степени аналитический, так в нем нет большого разнообразия окончаний, суффиксов. Очень важен порядок слов в предложении. Этим обуславливается большое разнообразие времен и форм глагола в английском языке. Грамматическое значение слова выражается за его пределами – например, с помощью предлогов, союзов, артиклей, вспомогательных глаголов и других служебных слов, а также с помощью порядка слов и общей интонации высказывания.

Русский язык – синтетический язык, так как в нем большинство слов имеют свои окончания, следовательно, основное грамматическое значение могут нести сразу несколько слов. Сравним некоторые моменты.

1.Отсутствие артиклей в русском языке: Холмс, безусловно, был не из тех, с кем трудно ужиться.- Holmes was certainly not **a** difficult man to live with. 2.Различия в употреблении времен: Его энергии не было предела, когда на него находил рабочий стих, но время от времени наступала реакция, и тогда он целыми днями **лежал** на диване в гостиной, не произнося ни слова и почти не шевелясь.- Nothing could exceed his energy when the working fit was upon him; but now and again a reaction would seize him, and for days on end he **would** lie upon the sofa in the sitting-room, hardly uttering a word or moving a muscle from morning to night.

3.Различный порядок слов в предложении: Редко когда он ложился спать после десяти вечера, **а по утрам**, как правило, успевал позавтракать и уйти, пока я еще валялся в постели.- It was rarefor him to be up after ten at night, and he had invariably breakfasted and gone out before I rose **in the morning.**

4.Различие при согласовании слов в предложении: Он вел спокойный, размеренный образ жизни и обычно был **верен своим привычкам.-** He was quiet in his ways, and his **habitswereregular**.

5.Отсутствие в английском языке таких морфологических признаков прилагательных, как род, число и падеж, а у существительных – падежа: В эти дни я подмечал такое **мечтательное**, такое **отсутствующее** выражение в его глазах. - On these occasions I

have noticed such a **dreamy**, **vacant** expression in his eyes. (Мечтательный – Dreamy, мечтательного – dreamy, мечтательными – dreamy).

Сравнив грамматический строй русского и английского языков, можно заметить, что большинство различий существуют в глаголах, существительных и синтаксисе, а меньше всего отличаются местоимения и числительные.

Таким образом, на примере рассмотренных единиц языка можно отчетливо представить, насколько разнообразны и выразительны грамматические средства современного английского и русского языков, насколько они схожи и различны между собой. Но, несмотря на различия между этими языками, они не перестают развиваться, взаимодействовать и украшать друг друга.

**Закиева Р.А.**
МБДОУ “Балтасинский детский сад №1 комбинированного вида”
Балтасинского муниципального района Республики Татарстан
учитель английского языка

## ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ИНФОРМАЦИОННО-КОММУНИКАТИВНОЙ ТЕХНОЛОГИИ MIMIO В ОБРАЗОВАТЕЛЬНОМ ПРОЦЕССЕ ДЕТСКОГО САДА

Занятие по английскому языку для детей старшей группы на тему
«Поле чудес»

**ЦЕЛЬ**: Закрепить изученный материал при помощи игр по темам: «Числа», «Игрушки», «Цвета».

**ЗАДАЧИ**:

- **обучающие:** продолжать формировать умения воспринимать английскую речь на слух, обучать диалогической и монологической речи, повышать интерес у дошкольников к изучению английского языка через игровые ситуации.
- **развивающие**: создать условия для развития коммуникативных умений и познавательной активности.
- **воспитательные**: воспитывать умение работать в группе, развивать чувство эмпатии

**МЕТОДЫ И ПРИЕМЫ**: ритмо-музыкальная игра, повторение и имитация, использование информационно-коммуникативной технологии MIMIO.

**АКТИВИЗАЦИЯ СЛОВАРЯ**: one, two, three ,four, five, six, seven, eight, nine, ten, red, pink, yellow, purple, green, blue, dolly, car, scooter, ball, train, What is your name? My name is…? How are you? I am fine ,thank you. What is it? This is a pink dolly. Red, pink, yellow, purple, green, blue

**ПРЕДВАРИТЕЛЬНАЯ РАБОТА**: закрепление речевых образцов и лексики по изученным темам, разучивание игр и песен.

**ОБОРУДОВАНИЕ**: доска, тематические картинки, записи песен на английском языке, декорации, компьютер, графический мимио планшет.

### ХОД ЗАНЯТИЯ

Куки встречает детей с обручем и с коробкой чисел.

Дети проходят через обруч, произнося волшебные слова, берут карточку с номером ,находят свой стул с номером и садятся.

Hello. My name is Azalija. I am a girl. My favourite color is red.

1.Приветствие

Песенка-приветствие « Hello, everyone!»

Teacher : Good morning, my dear friends! I’m glad to see you. Let’s sing our acting song!

Песня-игра: «Hello»

II.Фонетическая зарядка.
1. Mr.Tongue живёт в домике. Он просыпается утром, смотрит в окно и радуется:[ o: - o: - o: ]
С утра он выбивает половички на бугорочках расположенных за верхними зубками: [ d – d - d ]
Mr.Tongue доволен. Он говорит: [ g u d ]
Затем звонит в колокольчик, созывает гостей: [ n I ŋ - n I ŋ- n I ŋ ]
Гости приходят и здороваются: [ g u d m o n I ŋ ]

Работа в парах . Дети задают друг другу вопросы
-Hello.!
-Hello!
-What's your name?
-My name is…
-How are you?
-I am fine ,thank you.
-Are you a boy?
-Yes, I am a boy.
-What is your favourite color?
-My favourite color is blue.

III. Введение новой лексики и первичное закрепление.

Lulu what have you got in your pouch?
Whipping top-волчок.
Применяется графический мимио планшет.
На экране появляется волчок. (mimio studio)
Дети нажимают на волчок. Стрелка движется по кругу, играет музыка «Что? Где? Когда?»
На какой цвет и цифру остановится стрелка,то задание и выполняется.





Задания:
1. Игра «Roll the dice».(Работа с мимио студио)




Дети бросают кубик, называют число, затем считают карточки. На какую карточку выпадает номер, тот и называют.
2.Игра «Flashcard game».
На стульях разложены карточки (цвета, числа ,игрушки).Звучит музыка .Дети двигаются под музыку, музыка останавливается ,дети садятся на стулья и называют свою карточку.
3.Musical pause.
(Песенка игра « Find something blue»)

4.Игра « Let’s make a flower» (Работа с мимио студио)



Ребенок находит названный цвет и ставит свой лепесток на свое место.
Дети завершают свою работу. На экране звучат аплодисменты.




IV. Подведение итогов. Прощание.

Bye-bye , everyone. Tra-la-la-la-la
Bye-bye , everyone.Tra-la-la-la-la-la
Bye-bye , everyone. Tra-la-la-la-la
Bye-bye, everyone!

**Закирова Г.К.**
МБОУ «АНОШ №3-детский сад» г.Арск, РТ
учитель татарского языка и литературы

## БОЕРЫК ФИГЫЛЬ

**Максат**: боерык фигыль турында гомуми төшенчә бирү.

**Бурычлар:** 1.Иҗади фикерләү активлыгын, язма һәм сөйләм телен үстерү.
2. Милли-региональ компонентларга таянып, туган якка мәхәббәт тәрбияләү, якташ язучылар иҗатына кызыксыну , горурлык хисләре тәрбияләү.

Җиһазлау: интерактив такта, презентация,
Дәрес тибы: яңа теманы аңлату дәресе.
Форма: төркемнәрдә эшләү, парларда эшләү.
Дәрес барышы:

I. **Оештыру өлеше.**

- Уңай психологик халәт тудыру.
- Хәерле көн, хөрмәтле укучылар!

И минем җандай кадерле,
И җылы, тере телем.
Кайгылар теле түгел син,
Шатлыклар теле бүген
Тик синең ярдәм белән мин,
Тик синең сүзләр белән.
Уйларым , хыялларымны
Дөньяга әйтә беләм.

- Мин бүгенге дәресне Х.Туфанның телгә багышланган шигыре белән башлап җибәрдем. Ә бит без үзебез дә данлыклы Арча төбәгендә яшибез. Арча ягыннан бик күп танылган шагыйрьләр, язучылар чыккан.

- Әйдәгез, бергәләп Х.Туфан шигыренә нигезләнеп без дә шигырь язып карыйк. Мин сезне синквейн алымы белән таныштып китәсем килә.

Синквейн - француз сүзе, «биш илһам», «биш уңыш» дигәнне аңлата. Ул рифмалашмаган бишьюллык шигъри формада язылган кыска әдәби әсәр.

**Синквейн язу тәртибе:** Синквейн 5 юлдан тора

1. 1 сүз. Теманы ачыклаучы сүз, исем.
   - Нинди сүзләр исем дип атала?
2. 2 сүз. Теманы сурәтли торган 2 сыйфат.
   - Нинди сүзләр сыйфат дип атала?

3.3 сүз. Темага хас булган 3 фигыль.

- Нинди сүзләр фигыль дип атала?

4. 4 сүз. Темага карата үз мөнәсәбәтеңне белдерүче фраза, җөмлә

5. 1 сүз. Темага карата 1 синоним сүз (нәтиҗә, ассоциация).

- Нинди сүзләр синоним дип атала?

–Хәзер бергәләп төзеп карыйк.

**Телем.**
**Кадерле, тере.**
**Уйланам , хыялланам, сөйләшәм.**
**Мин үземнең телемне яратам.**
**Татар теле.**

-Афәрин, укучылар. Бүгенге дәресебезнең девизы итеп: **Мин татар телемне яратам дигән** сүзләрне алабыз. Ә телебезне беләбезме икәнен хәзер тикшереп карыйк.

**II. Актуальләштерү.**

1.Үткән дәрес материалын хәтердә яңарту. Сүз төркемнәре темасының моделен төзү.

- Укучылар, сез алдагы дәресләрдә сүз төркемнәрен өйрәнә башладыгыз. Әйдәгез, үткәннәрне искә төшрик һәм бергәләп белемнәребезнең моделен төзик. Синквейн төзегәндә без сезнең белән өйрәнелгән сүз төркемнәрен искә төшереп кабатлап киттек инде, хәзер каршыгызда биелгән модель- схемалар-ны төркемдә тутырып языгыз. Кайсы төркем беренчерәк бетерә, шулар беренче булып җавап бирәчәк.

(Слайд7)- Белемнәрне тагын да киңәйтеп кабатлыйк,экрандагы слайдка игътибар итегез. Төркемнәрдә акыл-штурмы үткәреп алырбыз. Мин чиратлап биргән сорауларга тиз генә җавап бирүегез сорала, сезгә ярдәмгә каршыгызда модель.

-Нәрсә ул исем? Исемнәр нәрсә белән төрләнә? Күплек сан ничек ясала? Ничә килеш бар?Нинди сүзләр сыйфат дип атала? Нинди сорауларга җавап бирәләр? Ничә дәрәҗә бар? Дәрәҗәләрне санап чыгыгыз. Алмашлыкларның нинди төркемчәләрен өйрәндегез? Зат алмашлаыкларын санап чыгыгыз. Саннар нинди сорауларга җавап бирәләр? Санның нинди төркемчәләрен беләсез? Нинди сүзләр фигыль дип атала?

**Ш. Яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру, уку мәсьәләсен кую.**

- Укучылар соңгы шакмакка игътибар итегез? Ни өчен бу шакмакта сорау билгесе? Бүгенге теманы беләбезме? Беләсегез киләме? Әйдәгез бергәләп яңа теманы ачыклыйк. Әйтеп киткәнебезчә без бөек Тукай ягында яшибез. Ул сезнең якташыгыз. Узган елны аның

“Кызыклы шәкерт” шигырен ятлаган идегез. Кем миңа беренче куплетын искә төшерер. Бәлки Акбай ролен дә уйнап күрсәтүче табылыр.

Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!
Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр йә өч кенә.

-Укучылар, экранда малайның сүзләрен күрәсез, тиз генә миңа фигыльләрне табып кем укып китәр?

- Өйрән, тор, аума, утыр .

- Безенең малай Акбайны нишли? (Өйрәтә) . Акбайга приказ бирә. Приказ ул безгә рус теленнән кергән алынма сүз. Каршыгызда русча –татарча сүзлекләр ята. Шул сүзлектән миңа кайсы пар тизрәк приказ сүзенең тәрҗемәсен табып укыр?

-Шулай булгач бүген без сезнең белән нинди фигыльләр белән танышырбыз? Темабыз ничек аталыр?

- Боерык фигыльләр.

-Ничек уйлыйсыз дәрестә нәрсә эшләрбез, нинди яңалыклар алырбыз?

**Нәтиҗә:** боерык фигыль боеру, эш кушуны, киңәш бирүне белдерә һәм нишлә? нишләмә? сорауларына җавап бирә. (тактага схема эленеп бара)

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү. Ныгыту**.

-Шулай итеп фигыльләр барлыкта һәм юклыкта килә дидек. Әйдәгез “ Ромашка” уены уйнап алыйк. Мин төркемнәргә ромашкалар бирәм, таҗларын өзеп, анда язылган сүзләрне укыйсыз, аннары боерык фигыльне юклык төрендә әйтәсез һәм ромашканы икенче кешегә бирәсез. Ә икенче төркем юклык формада бирелгән боерык фигыльләрне барлыкта әйтергә тиеш була.

- 1нче төркем: уйна, сөйлә, җырла, эшлә, бас;
2нче төркем: әйтмә, укыма, барма, язма, кимә.

**Нәтиҗә:** боерык фигыль барлык һәм юклык формада килә. Юклыкта фигыльләргә –ма,-мә кушымчасы ялгана ( схема эленә)

- Фигыльләр зат-сан белән төрләнәләр дип әйтеп киттек. Ә боерык фигыль төрләнәме икән? Моны ачыклар өчен мин сезгә карточкалар тәкъдим итәм. Бирелгән шигырь өзекләрен укып, боерык фигыльне укырга, нинди затта һәм санда икәнен әйтергә кирәк булачак.

1.И сабыйлар! **Эшләгез** сез, иң мөкаддәс нәрсә — эш,
Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китрер җимеш.

(Г. Тукай “Эшкә өндәү”)

-**Эшләгез** – боерык фигыль, 2 зат, күплек санда.

2. Һич сине **куркытмасыннар** шүрәле, җен һәм убыр;
Барчасы юк сүз — аларның булганы юктыр гомер.

- **куркытмасыннар** – боерык фигыль, 3 зат, күплек санда, юклык формада.

3. Син әле **үс** һәм **укы** күп, шунда аңларсың барын;
Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын.

(Г. Тукай “Сабыйга”)

-**үс, укы** – боерык фигыль, 2 зат, берлек санда.

4. **Тор**, шәкерт! Җиттек Казанга, алдымызда бит Казан”.
Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна;
«Әйдә **чап**, кучер, Казанга! Атларың **ку**: на! на-на!»

(Г. Тукай “Пар ат”)

-**тор, чап, ку** – боерык фигыль, 2 зат, берлек санда.

5. Яшь балалар! аларны сез **яратыгыз,**
Җылы сүзләр әйтеп, сөеп **юатыгыз**!
(Г. Тукай “Кышкы кич”)

- **яратыгыз, юатыгыз -** боерык фигыль, 2 зат, күплек санда.

**Нәтиҗә:** боерык фигыль зат-сан белән төрләнә.

**Тест.**

1. Боерык фигыль нәрсәне белдерә?

а)предметның билгесен.

ә)эш – хәлне, хәрәкәтне
б)боеру, эш кушу, үтентне.

2. Боерык фигыль нинди сорауларга җавап булып килә?
а)нинди?
ә)нишлә? нишләмә?
б)кем? нәрсә?

3. Боерык фигыльне тап.
а)аша.
ә) ашый.
б) ашады.

4. Җөмләдән боерык фигыльне табыгыз. Ул нинди фигыль?
Һич күләгә төшермә син җаныңдагы
Туган илең, Туган җирең яктысына.
а) хәзерге заман
ә) хикәя фигыль
б) юклык форма

5. **Ә син курыкма, батыр бул!** Бу җөмләдә боерык фигыль нинди мәгънә төсмере белдерә?
а) эш кушу, боеруны
ә) киңәш бирүне
б) үтенүне

Экрандагы дөрес җавапларны күзәтеп, укучылар бер-берсенең җавапларын тикшереп билге куялар.

**Дөрес җаваплар.**
**1. ә**
**2. ә**
**3. а**
**4. б**
**5. ә**

**V.Үзбәя.** Белемнәрегезне үзегез бәяләгез.

**VI. Рефлексия.**

- Каршыбызда бүгенге дәреснең моделе барлыкка килде. Кайсыгыз чыгып модель буенча бүгенге белемнәрне сөйләп китәр?
- Дәрестә бик актив катнаштыгыз. Үзегезгә ничәле билгесе куяр идегез?
- Төркемнәрнең командирына сүз бирик. Алар үзләренең белемнәрен ничек бәяләрләр?

**Җәләлеева Г.И.**
Арча районы Сеже төп гомуми белем мәктәбене
югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## САН СҮЗ ТӨРКЕМЕН ГОМУМИЛӘШТЕРЕП КАБАТЛАУ
## (VI сыйныфта татар теле)

**Максатлар:**
1.Сан турындагы белемнәрне ныгыту;
2. Сан төркемчәләрен дөрес билгеләү күнекмәләрен ныгыту;
3.Дуслык, бәхет төшенчәләрен ачу.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**
**Предмет нәтиҗәләре:**
– санны сөйләмдә дөрес куллана белү;

– белемнәрне системага салу күнекмәләрен камилләштерү.
**Метапредмет нәтиҗәләре:**
**Танып-белү:** күрә, аңлый, логик фикерли белү;
**Регулятив:** уку эшчәнлегенең әһәмиятен аңлап эшләү;
**Коммуникатив:** әйтергә теләгән фикереңне язма һәм телдән әйтә белүне оештыру, иптәшеңнең фикерен тыңлый белү.
**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**
– иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру;
– чын дулык хисе тәрбияләү.
**Материал һәм җиһазлау:** дәреслек (Татар теле.6 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Ф.Ю.Юсупов, Ч.М.Харисова, Р.Р.Сәйфетдинов; – Казан: Татар.кит. нәшр., 2014.-175 б., Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. 3 томда. Том 3. / Н.Исәнбәт. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2010. – 799 б., карточкалар, компьютер, экран
**Метод һәм алымнар**: әңгәмә, өлешчә эзләнү, мөстәкыйль эш, тест үткәрү.
**Дәрес тибы**: белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру- ориентлашу**
1. Исәнләшү.
2. Тәртип урнаштыру. Уңай халәт тудыру.
Хәерле көн, укучылар!

Әйдәгез эле, укучылар, игътибарыбызны экранга юнәлтеп алыйк. Сезгә тәкъдим ителәчәк видео безгә алга таба дәрес барышында кирәк булачак эле. Ни өчен кирәклеген алга таба сез әйтерсез. Бик игътибар белән карагыз. ( “38 Тутый кош” видеосы күрсәтелә. Видеода еланның буе 38 попугай адымы,5 маймыл һәм 2 фил озынлыгы кадәр)

**II. Актуальләштерү**
1. **Укытучы**: Укучылар, Сезгә шундый бер хикмәтле табышмагым да бар бит эле. Укып карагыз, уйлагыз да җавабын табыгыз! (Экранда табышмакларязылган слайд күрсәтелә).
**Мин** дөньяда барлык илләрнең байлыгы белән идарә итәм.
**Мин** кешеләрнең дөньяда яшәү вакытларын теркәп куям.
**Мин** барлык фәннәр белән дус яшим.
**Мин**нән башка кешеләр дәвалана да алмыйлар.
**Мин**нән башка кибеткә дә бара алмыйлар.
**Мин –** ярышта җиңүче дә.
**Мин** – укучыларны шатландыручы да, аларны борчуга салучы да.
Ә кайчакта **мин**... бик тәмле дә була алам.
Нәрсә соң мин?
**Көтелгән җавап:** Сан
**Укытучы:**Ә без саннар турында беләбезме сон? Бүгенге дәресебездә нишләрбез?
**Көтелгән җавап**: Сан сүз төркемен гомумиләштереп кабатларбыз
**2. Укытучы:** Дәфтәрләргә бүгенге дата, сыйныф эше, тема языла.
**3. Укытучы:** Цифрларны сез күбрәк кайсы дәрестә кулланасыз?
**Көтелгән җавап:** Математика.
**Укытучы:_** Укучылар, ә сез укый торган математика фәненең бик күптән барлыкка килүен беләсезме? Татар телендә беренче математика китабын язу өчен күп тырышлык куйган галим кем ул? Әйдәгез әле, экрандагы рәсем буенча аның кемлеген танып карыйк.
Слайдта – Каюм Насыйри (укучылар таныргa тиешләр). Сез аның кайсы әсәре белән таныш?
**Көтелгән җавап:** “Әбүгалисина”
**Укытучы**: Ә саннарсыз тормышта яшәп буламы?
**Көтелгән җавап:** Без иртән йокыдан торуга, алар безнең белән янәшә атлый башлый.
**Укытучы:** Гомумән, безнең бөтен тормышыбыз саннар белән бәйле икән. Менә шуңа күрә дә саннарны кулланганда, белемебез камиллеккә ирешерлек итеп, сан турында

өйрәнгәннәребезне ныгыту өстендә эшләрбез. Саннарның тагы да кызыклырак якларын ачарбыз.

**III. Уку мәсьәләсен адымлап чишү. Материалны ныгыту**

**1. Укытучы:** Без сан турында нәрсәләр беләбез соң? Әйдәгез, сан турында модельне искә төшерик.

Укучылар төркемләп урыннарда башкаралар һәм тактага чыгалар, аңлаталар.

**Көтелгән җавап:**

Сан

↓

предметның санын, исәбен белдерә

ничә? күпме? ничәнче? ничәләп? ничәү? ничәшәр? һ. б.

исем сүз төркемен ачыклый

җөмләдә аергыч була

сан белән ачыкланган сүз — саналмыш

белдерелә

сүзләр — бер, икенче, бишәр

цифрлар:
- гарәп — 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 0
- рим — I —1, V — 5, X — 10, L—50, C – 100, Д – 500, M - 1000

Үзбәя.

**2. Төркемнәрдә эш**

**Укытучы:** Алдагы бурычыбыз – саннарның төркемчәләрен искә төшерү. Мин сезгә “Сан төркемчәләре” лотосын өләшәм. Биредә һәр сан төркемчәсенә хас үзенчәлекләрне табып, лото рәвешендә сала барырга кирәк. (Тәртип саны+ предметларның саналу яки урнашу тәртибен белдерә+ ничәнче? + дүртенче, уникенче, йөзенче, егерме бишенче+ микъдар санына -ынчы/-енче, нчы/-нче кушымчалары ялганып ясала)

**3. Укытучы:** Күнегүләрне язып башкарыр өчен, безгә саннарның дөрес язылышын кабатлап китәргә кирәк. Сезнең өстәлдә таблица бирелгән.

Һәркем үзенең таблицасын тутыра. (слайд ярдәмендә тикшерелә)

**Көтелгән җавап:**

Саннарның ясалышы

| тамыр | кушма | парлы | тезмә |
|---|---|---|---|
| ↓ | ↓ | ↓ | ↓ |
| әйтелгәнчә языла | кушылып языла | сызыкча языла | аерым языла |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 дән 10 га кадәрге саннар, дистәләр, йөз, мең, миллион | 11 дән 19 га кадәрге саннар | бер-ике, ун-унбиш | егерме бер, утыз ике |

Үзбәя.

**4.Укытучы:** Сезнең алдыгызда раслаулар язылган таблица ята. Мөстәкыйль рәвештә эшләп алабыз. Әгәр раслау белән килешәсез икән “әйе” дигәнгә “+”, әгәр дә килешмәсәгез, “юк” дигәнгә “+“ куярсыз. Җавап бирер өчен сан турындагы белемнәрегезне искә төшерерсез.

**Көтелгән җавап:**

| **Бирем** | **әйе** | **юк** |
|---|---|---|
| Сан сүз төркеме предметны белдерә | | + |
| Алты-җиде – парлы сан | + | |
| Сан ачыклаган исем аныклагыч була | | + |
| Саннар сүзләр белән дә, цифрлар белән дә языла | + | |

| | | |
|---|---|---|
| Саннарны язу өчен, гарәп һәм рим цифрлары кулланыла | + | |
| Ясалышы ягыннан саннар алты төрле була | | + |
| 25 елның синонимы – чирек гасыр | + | |
| Сан җөмләдә бары тик аергыч булып килә | | + |
| Саннарны җөмләдә синонимнар белән алыштырып була | + | |

**" юк"** җавапларын дөресләп барабыз. Сораулар:
**Укытучы:**Сан сүз төркеме нәрсәне белдерә?
**Көтелгән җавап:** Предметның исәбен, санын белдерә.
**Укытучы:**Сан ачыклаган исем ничек йөртелә?
**Көтелгән җавап:** Саналмыш.
**Укытучы:**Саналмышсыз килгәндә, сан нишли?
**Көтелгән җавап:** Исемләшә.
**Укытучы:** Сан җөмләдә нинди җөмлә кисәге булып килә?
**Көтелгән җавап**: Саналмышы белән килгән саннар җөмләдә аергыч була, саналмышсыз килгәндә, сан исемләшә, төрле җөмлә кисәге була.

**Физкультминутка**

**5. Укытучы: Экрандагы текстны укыйбыз.**
Бик биек тауда бер көтүче яшәгән. Бервакыт яңгырлы төндә өч кеше аның ишеген шакыган.
-Минем өем бик бәләкәй, берегез генә керегез.
- Сез кемнәр соң?- дип сораган көтүче.
- Без- Дуслык, Бәхет һәм Байлык. Иң башлап кайсыбыз керүен үзең хәл ит...
**Укытучы:** Көтүче кемне сайлаган?
**Көтелгән җавап:**Дуслыкны.
**Укытучы:** Ни өчен?
**Көтелгән җавап**: Дуслык керү белән, өйгә Бәхет тулган, Байлык килгән.
**Укытучы:** Ә хәзер укучылар, дуслык формуласын төзеп карыйк. Сезнең алда "Дуслык агачы". Без аларны җимешләр белән бизәргә тиеш. Моның өчен дуслык турында мәкальләр уйлап карыйк.

1. Йөз сум акчаң булганчы, 100 дустың булсын.
2. Дусты булмаган кеше - ярты кеше.
3. Балык - сусыз, кеше дуссыз тора алмый.
4. Бозылышкан дус дошманнан яман.
5. Дус - акчадан кыйммәт.
6. Дус биткә карар, дошман акчага карар.
7. Дусларын онытканның үзен дә онытырлар.
8. Дусың авырса, син дә ыңгыраш.
9. Ил өстендә илле дустың булсын.
10. Матурлык - бер көнлек, дуслык - гомерлек.
11. Кешенең иң зур дәүләте – чын дусты.

**Укытучы:** Рәхмәт, укучылар. Бик күп мәкальләр беләсез икән. Дуслык – бик изге һәм тиз уалучан хис. Чын дуслар булу өчен дустыңны яратырга, хөрмәт итәргә, авыр чакта ярдәм кулын сузарга, дуслыкны сакларга кирәк.

**6. Укытучы.** Хәзер исә санга морфологик анализ ясау тәртибен искә төшерик. (Алда китерелгән өзектән санны табып, морфологик анализ ясыйлар)
**Көтелгән җавап:** Бер (көтүче) - сан, микъдар саны, исемләшмәгән, аергыч, тамыр.
**IV. Рефлекция**

**1.Укытучы:**Дәрес башында караган мультфильмны искә төшерегез әле.Укучылар, бу өзекне сезгә ни өчен китердем икән?
**Көтелгән җавап**: Саннарның тормышта кулланылышын ачу өчен.

**Укытучы:**Укучылар, дәресебез ахырына якынлаша, сезнең кәефләрегез ничек? Сезнеңчә, алдыбызга куйган максатларга ирешә алдыкмы? Биремнәрне эшләгәндә, авырлыклар тудымы? – Сез дәрестә бик тырыш булдыгыз, зур рәхмәт сезгә. Күтәренке кәеф белән дәресне тәмамлыйк.

**2. Билгеләр кую: үзбәя һәм укытучы бәясе**

**Укытучы:**Әйдәгез, укучылар, үз эшебезгә бәя бирик. Сезнең алда үзбәя картасы ята. Үзегезнең эшчәнлегегезгә туры килгән бәяне сайлап алыгыз. Мин сезнең дәрес барышындагы җавапларыгызны искә алып һәм үзбәяләрегезне исәпләп, билге куярмын.

6 нчы сыйныф Исемем: _______________

| | балл |
|---|---|
| Мин бу дәрестә актив катнаштым | |
| Биремнәрне үтәгәндә үземнән өлеш керттем | |
| Мин санга морфологик-синтаксик анализ ясый беләм | |
| Сөйләмем дөрес һәм тулы булды | |
| Саннарны сөйләмдә дөрес итеп куллана беләм | |

(Һәр пункткаберешәр баллдан)

**V . Өй эше**

а) мәҗбүри -155 нче күнегүдә саннарга морфологик анализ ясарга;

б) ярымиҗади – сан кергән җырлар, шигырьләр табып килергә;

в) иҗади бирем –саннарны кулланып, “Чын дустым” дигән хикәя төзергә;

**Зарипова Г.Г.**

Филиал МБОУ «Гимназия с. Большой Сардек имени К.Ф.Шакирова», Кукморского муниципального района Республики Татарстан в с.Копки, учитель начальных классов

## ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ИНФОРМАЦИОННО-КОММУНИКАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ НА УРОКАХ В НАЧАЛЬНОЙ ШКОЛЕ

Перед современной школой стоит очень важная задача – подготовка подрастающего поколения к жизни в быстро меняющемся информационном обществе, в мире, в котором ускоряется процесс появления новых знаний, постоянно возникает потребность в новых профессиях, в непрерывном повышении образования. Как показывает практика, без новых информационных технологий уже невозможно представить себе современную школу

Важная цель обучения в начальной школе – научить каждого ребёнка за короткий промежуток времени осваивать, преобразовывать и использовать в практической деятельности огромные массивы информации. Детям приходится часто самим находить необходимую информацию по различным темам. Задача учителя начальной школы – умело сочетать работу с книгой и поиск информации детьми с помощью техники.

Использование компьютера освобождает учителя от рутинной работы на уроке: запись, стирание с доски. Делает его свободным в выборе наглядного материала. Компьютер дает учителю новые возможности, позволяя вместе с учеником получать удовольствие от увлекательного процесса познания, не силой воображения, а с помощью компьютерных технологий, позволяет погрузиться в яркий красочный мир.

Я работаю учителем тридцать три года. Мне всегда было интересно заниматься чем-то новым и увлекательным, делать свои уроки насыщенными, продуктивными, современными. Ведь задача учителя состоит в том, чтобы заинтересовать детей своим предметом, привлечь внимание учеников, чтобы они захотели получать предложенные им

знания и учились добывать их сами. Поиск эффективных методик привел меня к новым компьютерным технологиям, которые эффективно применяются при организации творческой познавательной деятельности учащихся в процессе изучения различных школьных дисциплин.

В своей работе я использую компьютерные технологии на каждом предмете.

На уроках математики применяю компьютерные технологии. Составляю интересные игры для устного счета, например, «Зажги фонарики», « Цветочки», составление таблицы на сложение и т.д., решение математических познавательных цепочек. Могут быть организованы математические разминки и самопроверка. Яркое анимированное оформление способствует более полному восприятию и запоминанию нового материала урока.

